ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
М. Х. ХӘСӘНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ
ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ

**Р. Ф. Исламов**

# КАЮМ НАСЫЙРИ

*Биобиблиографик күрсәткеч*

Казан
2024

УДК 82(=512.145)"18/20"01
ББК 83(=632.3)я1
И87

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
М. Х. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе
һәм төбәкне өйрәнү институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла

*Редколлегия:*
Э. М. Галимова, Л. М. Айнетдинова,
М. Ш. Сибгатуллина, Р. В. Шәйдуллин

**Исламов Р. Ф.**
И87 Каюм Насыйри: Биобиблиографик күрсәткеч. – Казан: ТР ФА М. Х. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2024. – 160 б. + 8 б. ил.

Биобиблиографиядә татар халкының бөек мәгърифәтче галиме, язучы, тел белгече, тарихчы, этнограф, педагог Каюм Насыйриның (1825–1902) биографиясе, нәшер ителгән әсәрләре, хезмәтләре, календарьлары, мәкаләләре, тормышы һәм иҗаты турында дөнья күргән монографик хезмәтләр, гыйльми җыентыклар, якланган диссертация авторефератлары, мәкаләләр хакында мәгълүмат тупланган. Алар хронологик яктан галим үзе яшәгән чордан алып хәзерге кадәрге вакытны иңли. Хезмәт К. Насыйри шәхесен һәм иҗат эшчәнлеген өйрәнүчеләргә, әдәбият галимнәренә, аспирантларга, укытучыларга, студентларга тәкъдим ителә.

**УДК 82 (=512.145)"18/20"01**
**ББК 83 (=632.3)я1**

**ISBN** 978-5-902375-78-4

© ТР ФА М. Х. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2024
© ТР ФА, 2024
© Р. Ф. Исламов, 2024

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫ ӨЙРӘНҮ
## ҺӘМ АНЫҢ БИОБИБЛИОГРАФИЯСЕ

(*Кереш сүз урынына*)

XIX йөз – Россия тарихында гомумән, татар иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында аерым алганда, зур үзгәрешләр чоры буларак характерлана. Үзенең күпкырлы эшчәнлеге белән танылган, бөтен тормышын, талантын үз халкын агартуга багышлаган мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкилләреннән берсе Каюм Насыйри милли-рухи тормышыбыз мәйданына шул вакытларда чыга.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров 1825 елның 2 (14) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында (хәзер – Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы) мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне атасыннан ала. Аннары белем эстәүне 1841–1855 елларда Казанның бишенче мәхәллә мәчете имамы Әхмәт бине Сәгыйть бине Әхмәт бине Йосыф әш-Шырдани (1787–1867)[1] мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Дөрес, туганнары һәм үзе язган хатлардан аңлашылганча, ул башта шул заманның данлыклы Кышкар[2] мәдрәсәсенә укырга барырга ниятләгән була. Бер үк вакытта Казан университетында ирекле тыңлаучы сыйфатында лекцияләргә йөри.

1855 елда мәдрәсәне тәмамлагач, аны Казандагы Руханилар училищесына татар теле укытучысы сыйфатында эшкә чакыралар. Аннары ул әлеге уку йортының дәвамы булган Руханилар семинариясендә мөгаллим була. Анда, рус педагоглары белән тыгыз элемтәгә кереп, алар ярдәмендә рус те-

[1] Аның хакында тулырак кара: Фәхреддин Р. Асар / Фәнни мөх. М. Госманов; төз.: И. Гыймадиев, Р. Миңнуллин, С. Баһавиева. – Казан: Рухият, 2009. – 2 т. – Б. 115–116.

[2] *Кышкар* – элекке Казан губернасы Казан өязенә (хәзерге Татарстан Республикасы Арча районы Яңа Кишет җирле үзидарәсе) караган авыл. Ул элгәре үзенең мәдрәсәсе белән танылa.

лен һәм башка фәннәрне өйрәнүне дәвам иттерә, белгәннәрен камилләштерә. Бу уңайдан бер кызыклы фактны әйтеп үтү урынлы булыр. Тел белгече һәм рухани П. П. Масловский (?–1889) анда укыганда татар теле дәресләрен К. Насыйридан ала. Әмма башка предметлардан баллары югары булса да, монысына 6 һәм 8 балл гына куела, чөнки болар мөгаллимнең яхшы билгеләреннән санала[1].

Алар арасында дустанә мөгамәлә урнашкан булса кирәк. Чөнки «Масловский үзенең «дусты» Насыйров әңгәмәләре белән татар теле буенча сыйныфта шөгыльләнүләрен генә тулыландырып калмый, аларны семинарияне тәмамлаганнан соң да дәвам иттерә. Алай гына да түгел, Насыйровның әдәби хезмәтләренә кушыла һәм аның татар халык иҗаты ядкярләре җыентыгын педагогик максатларда эшкәртә»[2]. Ул, бу хакта сүз йөртеп, К. Насыйриның хезмәтләрен нәшер итү зарурлыгын әйтә: «Бу лекцияләр өчен материал кайдан алырга?» «Казан губернасы крестьяннары көнкүреше»ндә татарлар кош очышы югарылыгыннан тасвирлана; әмма хезмәт сөюче Насыйровның татар этнографиясе хакындагы язмалары киңрәк һәм ышанычлырак. Аларны нәшер итәргә кирәк иде. Шулай ук Насыйровның «Татарча-русча лөгат»ен дә бастырырга кирәк иде…»[3]

К. Насыйри, Руханилар семинариясендә эшләүдән 1870 елда туктап, 1871 елда татар балаларын русча укыту өчен башлангыч мәктәп оештыра. Бу вакытта ул, үзе язганча, Сәгъди Яхин[4] дигән кеше фатирында яши һәм дүрт-биш укучысы бу-

---

[1] Харлампович К. В. П. П. Масловский и его переписка с Н. И. Ильминским (Материалы для истории русской миссии) / К. В. Харлампович // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. – Казань: Типо-литогр. Имп. Казан. ун-та, 1907. – Т. XXIII. – Вып. 1. – С. 69.

[2] Харлампович К. В. Күрс. хезм. – Б. 76.

[3] Харлампович К. В. Күрс. хезм. – Б. 94.

[4] *Сәгъди Яхин* – бу кеше хакында әлегә мәгълүматыбыз юк.

ла. Аннары, Сая Ибрай[1] номерына күчкәч тә, өч шәкерте була. Закир хәзрәт[2] мәхәлләсендәге Балан Шаһи исемле кешенең йортында рус-татар мәктәбендә укыта[3]. 1872 елның февраль башына кадәр тиешле урын таба алмый йөргәннән соң, ниһаять, Мо̀крый[4] урамындагы бер кабак өстендә фатир алып, унлап бала укыта башлый. Аннары килешү нигезендә икенче гильдия сәүдәгәр Шаһиәхмәт Салихов (1825–1885) тарафыннан Захарьевская урамында төзеттерелгән ике катлы агач өйдән[5] вакытлыча урын ала. Анда егерме-егерме биш бала укый башлый. Әйтергә кирәк, эшләр уңай гына бармый. Төрле яктан һәрдаим куркытулар булып тора, хакимияткә шикаятьләр бирелә. Җәй узгач, шул ук урамдагы тагын икенче фатирга күченә һәм анда укырга утызлап малай җыела.

К. Насыйри Казан татар укытучылар мәктәбендә дә эшли. Ләкин, кайбер мәгълүматларга караганда, ул В. В. Радлов (1837–1918)[6] тәкъдим иткән укыту ысулы белән килешмичә, 1876 елда аннан китә һәм 1879 елдан, беркайда да рәсми хезмәттә булмыйча, иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый.

1880 елда Санкт-Петербургта «Император рус география җәмгыяте язмалары»ның 6 нчы томында аның «Казан татарларының тормышларына сөнни ислам тәэсиреннән тыш барлыкка килгән ышанулары һәм йолалары» дигән саллы хезмәте басылып чыга[7].

---

[1] *Сая Ибрай* – бу кеше хакында әлегә мәгълүматыбыз юк.

[2] *Закир хәзрәт* – сүз «Зәңгәр» мәчет (4 нче мәчет) имамы Мөхәммәтзакир Хаммат улы Халидов (?–1893) турында бара булса кирәк.

[3] Әл-Кәчимири Габдулла бине Таҗетдин. Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. – 1913. – № 10. – Б. 292.

[4] Хәзерге Сакко һәм Ванцетти урамы.

[5] Хәзерге Каюм Насыйри урамы, 20 нче йорт.

[6] *В. Радлов* – Василий Васильевич Радлов (Фридрих Вильгельм, 1837–1918) – шәркыятьче-тюрколог, тел галиме, этнограф, археолог. Казанда (1871 елдан) яшәгәндә Казан уку-укыту округының татар, башкорт һәм казакъ мәктәпләре инспекторы.

[7] Насыров К. Поверья и обряды Казанских татар, образо-

К. Насыйриның гыйльми эшчәнлеген югары бәһаләп, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте 1885 елның 3 ноябрь утырышында аны бертавыштан үзенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлый һәм 1896 елның 27 октябрендә шуны раслаган Диплом тапшыра. Шул рәвешле ул рәсми яктан фән кешесе буларак танылa.

1896 елда әйтелгән җәмгыять «Хәбәрләр»ендә К. Насыйриның «Казан татарлары халык әдәбияты үрнәкләре»[1] дигән мәкаләсе дөнья күрә. Профессор Н. Ф. Катанов (1862–1922) аңа язган кереш өлешендә болай дип билгели: «Хәзер Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә хакыйкый әгъза Габделкаюм Насыйров тарафыннан шушыларны үз эченә алган мәкалә тәкъдим ителә: 28 табышмак, 243 мәкаль һәм 145 җыр. Насыйров әфәнде Казан татарлары халык иҗаты ядкярләрен үзеннән элгәре җыючыларга караганда беренче мәртәбә шундый күп мәкаль һәм җырлар тәкъдим итте. Насыйров әфәнде тәкъдим иткән материаллар белән аның үзе гомер буе алар арасында яшәгән халкының көнкүреше һәм телен яхшы белүен тулысы белән дәлилли»[2].

Үзеннән элгәреләр дигәндә, Н. Ф. Катанов мажар галиме Габор Баллинт (1844–1913) һәм аның 1875 елда Будапешт шәһәрендә дөнья күргән китабы[3], тарихчы һәм филолог Габделгаллә Фәезханов (1850–1910) һәм аның 1890 елда нәшер ителгән китабы[4], педагог Габдүш Вәһапов (1814–1876) һәм

---

вавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства / К. Насыров // Зап. Имп. рус. геогр. об-ва. По отд. этнографии. – СПб., 1880. – Т. 6. – С. 243–270.

[1] Насыров А. К. Образцы народной литературы казанских татар / А. К. Насыров // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. – Казань: Типо-литогр. Имп. Казан. ун-та, 1896. – Т. XIII. – Вып. 5. – С. 376–427.

[2] Насыров А.К. Образцы народной литературы казанских татар… – Б. 375.

[3] Bálint G. Kazáni-tatár nyelvtanulmányok. I. Fuzet. Kazáni-tatár szøvegek / G. Bálint. – Budapest, 1875. – 178 p.

[4] Фәезханов Г. Хикәят вә мәкаләт / Г. Фәезханов. – Казань: Тип.

аның 1892 елда басылган татарча-русча үзөйрәткече[1], телче һәм фольклорчы Мөхәммәтшакир Салихов (? – 1929) һәм аның 1880 елда басылган мәкальләр, әйтемнәр һәм табышмаклар җынтыгы[2] хакында сүз алып бара.

Н. Ф. Катанов үзенең «Казан татарларының тарихи җырлары»[3] дигән мәкаләсендә китергән ике, ягъни «Казан бәете» һәм «Николай бәете» дигән әсәрләрне К. Насыйриның 1881 елгы календареннан алганлыгын яза.

1899 елда нәшер ителгән «Хисаплык» дигән китапның уңай якларына игътибарны юнәлтеп, Н. Ф. Катанов болай ди: «Элекке гарәп телендә булмыйча, яңача Европа ысулында язылган, бигрәк тә киң катлауга аңлаешлы татарча бу китап танылган Казан галиме Габделкаюм Насыйровныкы… Терминнар барысы да бик уңышлы сайланып, моңа кадәр булган дәреслекләрдә аңлашылмый торган борынгы гарәпчә урынына, асыл татарча сүзләрдән төзелгән. Гомумән, Насыйровның дәреслеге татар педагогикасында игътибар ителергә тиешле гаять файдалы яңалык булып тора»[4].

«Осуле җәгърәфияи кәбир» дигән хезмәте хакында сүз йөртеп, Н. Ф. Катанов аның Кятиб Чәләби тәхәллүсе белән билгеле булган төрек галиме Мостафа бине Габдуллаһ Хаҗи-Хәлфәнең (?–1658) «Җиһаннамә» дигән хезмәтеннән файдаланып төзегәнен күрсәтү белән бергә «Г. К. Насыйров кайва-

---

Г. М. Вечеслава, 1890. – 31 б.

[1] Самоучитель для русских по-татарски и для татар по-русски. Сост. Вагаповым = Үзе-үзедин өйрәткеч татарлар урысча һәм урыслар татарча сөйләшергә. Истираҗ итүче Габдүш Әхтәм угылы Ваһапов. – Казань: Тип. Г. М. Вечеслава, 1892. – 64 б.

[2] Салихов М. Табышмаклар һәм мәкальләр / М. Салихов. – Казан, 1880.

[3] Катанов Н. Исторические песни казанских татар / Н. Катанов // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. – Казань: Типо-литогр. Имп. Казан. ун-та, 1907. – Т. XV. – Вып. 3. – С. 273–306.

[4] Катанов Н. Хисаплык (Числительница, или арифметика) / Н. Катанов // Деятель. – 1900. – № 6–7. – С. 336–337.

кыт Кятиб Чәләби әсәренә, үзенең сүзләренә күрә, ышанычлы китаплардан алынган яңа мәгълүмат та өсти»[1], – дип яза.

Шул чор рус галимнәренең К. Насыйри хакында уңай фикерләре белән бергә, аның хезмәтләрен башка юнәлештәрәк, ягъни миссионерлык мәнфәгатьләрен истә тотып файдаланырга тырышу омтылышларын да күрми мөмкин түгел. Мәсәлән, тарихчы-шәркыятьче, профессор В. В. Григорьев (1816–1881) аның Санкт-Петербургта басылып чыккан хезмәтенә язган кереш мәкаләсендә болай ди: «Казан университетында алган Европа белеме аны акыл мөнәсәбәтендә шундый югарылыкка күтәргән – ул исламга объектив карый торган безнең мөселманнардан беренчесе… Аның фәнни рухтагы тикшеренүләренең мөселманлыкны пропагандалау мәгънәсендә кулланылу ихтималы турында шикләнүгә бернинди дә сәбәп юк»[2].

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан (1886–1926) К. Насыйриның әдәби һәм фәнни эшчәнлеген болай бәһали: «Әдәбиятымыз күп гасырлар Шәрык тәэсире белән килгәннән соң, акрын гына Гареб тәэсире астына керә башлыйдыр.

Әдәбиятымызның бу гасыр (период) мәрхүм Габделкаюм ән-Насыйри белән башланды. Насыйри гарәпчә вә русча яхшы белгән зыялы бер зат булганлыктан, әсәрләрен дә Шәрыктан күп нәрсәләр истифадә[3] иткән шикелле – рус әдәбиятыннан да файдаланадыр. Мәсәлән: җәгърәфия, гыйльме әтбихәлә даир[4] календарьлар, словарьлары бөтенләй рух әсәрләреннән истифадер.

---

[1] Катанов Н. «Усули джаграфия-и кебир» (Основы большой географии). Казань, 1899. Типо-литогр. ун-та. 138 стр. $6^0$ / Н. Катанов // Деятель. – 1900. – № 10. – С. 451.

[2] Григорьев В. В. Предисловие / В. В. Григорьев / Насыров К. Поверья и обряды Казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Зап. Имп. рус. геогр. об-ва. По отд. этнографии. – СПб., 1880. – Т. 6. – С. 241–242.

[3] *Истифадә* – файдалану.

[4] *Даир* – бәйләнешле.

Насыйри үзенең озак фәүкыльгадә[1] тырышлык белән иткән хезмәте аркасында халык тарафыннан вакытында тәкъдир ителмичә генә, татарларга бик күп нәрсәләр һәдия[2] иткән. Ул иң әүвәл татарларны рус теле белән белештермәкче булып «Словарь», «Әнмүзәҗ» тәртип итүче. Ул иң әүвәл татарларга үзләренең бер телләре бар икәнен белдертер өчен – «Ләһҗәи» вә «Фәвакиһе җөләса» тәэлиф[3] итүче. Вә ул ук иң әүвәл әсәрләрен татарча яза башлап, һәр язу таныган кеше истифадә итәрлек тарызда[4] ясаучы. Җәнабе Хак аны рәхмәт итсен.

Озын гомерен татар әдәбияты хезмәтенә фида иткән (халык тарафыннан, аның ничек тәкъдир ителгәнен яхшы күрсәтерлек, үз мәгыйшәтемнән[5] бер вакыйга хәтеремә төште. Мәдрәсәдә торган заманнарымның соңында бервакыт базардан «Ләһҗәи татари» алып кереп карарга тотынган идем. Шәрикләремнән озын гына буйлы, бик дәгъва[6], таза бер мишәр яныма килеп, нәрсә моталәга[7] итдекемне сорашты. Мин дә бәян иттем. Ул китапны алып ачты да иттифакый[8] «йомрык» дигән сүзгә күзен төшерде. Тәрҗемәсен укып карагач, күзләрен челәйтеп вәхшиянә йозырыгын җомарлап: «Мона аны китаптан укып beләсе юк, белмисең икән, күреп кал!» – дип күз төбемең китереп, һәм минем гомеремнең юкка заегъ[9] булуына тәәссеф[10] иткәнлеген вә «дамелла» булса, бу эшем өчен миңа җәза биргән булыр иде икәнлеген бәян итте. Мона татар шәкертләре татар әдәбияты белән нинди мөнәсәбәттәге заманнары бар иде). Шулай да

---

[1] *Фәүкыльгадә* – гадәттән тыш.
[2] *Һәдия* – бүләк.
[3] *Тәэлиф* – төзү.
[4] *Тарызда* – рәвештә.
[5] *Мәгыйшәт* – тормыш.
[6] *Дәгъва* – низаг, дау.
[7] *Моталәга* – уку, өйрәнү.
[8] *Иттифакый* – очраклы.
[9] *Заегъ* – бушка, файдасызга.
[10] *Тәәссеф* – үкенү.

Насыйри әфәнденең әсәрләрендә Шәрык стилендә тәртип ителгән җөмләләргә күп [о]чрарга мөмкиндер»[1].

Танылган тел галиме Л. Җәләй (1894–1966) татар әдәбиятында дидактик жанрны куллана башлауны К. Насыйри иҗаты белән бәйләп аңлата һәм моңа мисал итеп аның «Буш вакыт», «Кырык бакча» әсәрләрен китерә. «Татарда хыялый романнар язу кайчаннан һәм кемнәрдән башлана дигән сорауны бирүчеләр дә беренче җавапны Насыйри «иҗат бүлмәсеннән» барып табачак»[2], дип галим беренче чиратта «Гөлрох һәм Камәрҗан» әсәрен күрсәтә.

К. Насыйри үзенең хезмәтләрендә иллюстратив материал буларак шул чорда дөньяви рухтарак язылган әсәрләрне дә файдалана. Бу уңайдан татар халык шагыйре Г. Тукай (1886–1913) үзенең «Исемдә калганнар» автобиографик әсәрендә янә Кушлавычка Бәдри абзыйларга кайткач булган бер вакыйганы шулай тасвирлый: «Кич белә китаплар актарганда, кулыма «Фәвакиһел-җөләса» китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм вә аңларга тырышам, фәкать мин Кырлайда чакта тик «Газизә»[3] вә вә «Сөбател-гаҗизин»нәр генә укыганга, бу китаптагы оят сүзләргә гаҗәпләнәм вә, китапта шундый сүзләр дә була микәнни? – дип, үземә сөаль бирә идем»[4]. Сүз, әлбәттә, ша-

---

[1] Дамелла. Әдәбиятка гаид / Дамелла // Әл-Ислах. – 1908. – № 47. – Б. 3–4.

[2] Җәләй Л. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри / Л. Җәләй // Совет әдәбияты. – 1945. – № 2. – Б. 43.

[3] *«Газизә» [«Рисаләи Газизә»]* – Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838) тарафыннан Урта Азия шагыйре Суфи Аллаһиярның (1630 еллар – 1721 яки 1723) «Сөбател-гаҗизин» («Көчсезләрнең ныклыгы») дигән шигъри әсәренә шәрехләр язылган китап. Аңлатмасында язылганча, ул аны кызы Газизә үтенече белән башкарганга, «Рисаләи Газизә» дип атый.

[4] Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда / Төз., иск. һәм аңлат. язды Р. Гайнанов / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 5 т.: Истәлекләр, юлъязмалар, хатлар, мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902–1913). – Б. 26.

гыйрь Габделҗәббар Кандалыйның (1797–1860) «Сәхибҗәмал» дигән поэмасы хакында бара[1].

К. Насыйри бу хезмәтендә шулай ук «Чәй бәете»ен[2] дә урнаштырган. Нәкъ шул ук әсәр Г. Фәезханов тарафыннан нәшер ителгән «Хикәят вә мәкаләт» дигән китапта да бар[3]. Ул аны Казанның бер мулласыныкы икәнлеген белдерә. Ләкин, ике текст та бер үк булуга карамастан, анда сүзләр кулланылышында аермалар күзәтелә[4].

К. Насыйриның татар телендә газета чыгару идеясе белән дә йөргәнлеге мәгълүм. Ул Казан Руханилар училищесында укытучы булып эшләгән вакытта, алар литография хуҗасы, Казан мещаны Мөхәммәтвәли Мозаффар улы Яхин (?–?) белән берлектә «Таң йолдызы» дигән газета чыгарырга рөхсәт сорап Казан хәрби губернаторы П. Ф. Козлянинoвка (1808–1864 елдан соң) үтенеч белдерәләр. Әмма патша хөкүмәте моңа ризалык бирми[5]. Шулай булуга карамастан, бу омтылыш 1905 елларда татар вакытлы матбугаты[6] нигезләнә башлану үрнәкләрнең берсе була.

Академик Ә. Г. Кәримуллин (1925–2000) язганча, «газетаның программасына карап, шуны әйтергә мөмкин, газета нә-

---

[1] Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият. Мөстәтраф вә раузел-әхйар китапларыннан интихаба тәэлиф кылынып кырык рауза үзеренә мөрәттиб мордәдәлларның калебләрен әхйа кыйлыр бер китаптыр вә Габделкаюм мелла Габденнасыйр угылының каләм фәкыйранәсеннән җәрәян итмеш бер әсәрдер. Ошбу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1884 нче елда. – Б. 559–579.

[2] Фәвакиһел-җөләса... – Б. 557–558.

[3] Фәезханов Г. Күрс. хез. – Б. 11–13.

[4] Бу хакта тулырак: Катанов Н. Полезно-ли пить чай? (Татарские рассуждения) / Н. Катанов // Деятель. – 1897. – № 1. – С. 48–49.

[5] Бу хакта тулырак: Кәримуллин Ә. Каюм Насыйриның «Таң йолдызы» проекты / Ә. Кәримуллин // Казан утлары. – 1975. – № 2. – Б. 157–162.

[6] Бу хакта тулырак: Амирханов Р. У. Татарская демократическая печать (1905–1907 гг.) / Р. У. Амирханов. – М.: Наука, 1988. – 191 с.

шер итүнең максаты – татарларны Россиянең иҗтимагый тормышы белән таныштыру, беренче чиратта – татарлар арасында дөньяви белем тарату, әдәби әсәрләрне пропагандалау, дөньядагы фән һәм мәдәният казанышлары белән таныштыру. Чит илләрдәге халыклар тормышы хакында мәгълүмат бирү бурычы да куела. Библиография һәм тәнкыйть бүлегеннән күренгәнчә, ул әдәби-публицистик орган булырга тиеш»[1].

Бу ният гамәлгә ашмагач, К. Насыйри 1870 елдан календарь төзеп бастыра башлый. 1886, 1887, 1895 еллардан башка аның егерме дүрт басмасы дөнья күрә[2].

К. Насыйрига китапларын җибәрүен үтенеп язылган күп хатларның Россия империясенең төрле төбәкләреннән килүе шул чорда аның хезмәтләренә ихтыяҗның зур булганлыгын дәлилли. Календарьларының шулай ук Урта Азиядә дә таралыш алганлыгы мәгълүм[3].

К. Насыйриның үз гаиләсе мәсьәләсенә килгәндә исә, төрле фикерләр бар. Мәсәлән, М. Парсин (1899–1963) аның, 1863 елда өйләнеп, унбер айдан соң хатыны вафат булгач, бүтән җәмәгатьләнмәве хакында әйтә[4]. Әдәбият галиме М. Гай-М. Гайнуллин (1903–1985) аның 1865 елда Казанның ямщик Мөсәгыйть кызы Зөһрәгә никахланганлыгын, әмма бер елдан

---

[1] Каримуллин А. Татарская книга пореформенной России: Исследование / А. Каримуллин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. – С. 185.

[2] Бу хакта тулырак: Миннуллина Л. Календарные издания просветителя К. Насыри // Миннуллина Л. Татарские печатные календари XIX – начала XX вв. / Науч. ред. З. С. Миннуллин. – Казань: Заман, 2015. – С. 71–87.

[3] Кубатова А. З. Татарское просветительство и реформаторское движение в Кыргызстане (конец XIX – начало XX века) / А. З. Кубатова. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2022. – С. 102–103.

[4] Латыйф Г. Каюм Насыйрины искә төшерү турында зур җыелыш / Г. Латыйф // Кызыл Татарстан. – 1925. – 18 февр.

соң хатыны баладан үлүен һәм шуннан соң К. Насыйриның ялгыз, гаиләсез яшәве турында яза[1].

Дин әһеле, публицист һәм журналист Насыйретдин әл-Хуҗаши (?–?) истәлегеннән күренгәнчә, әлеге мәсьәләгә карата биргән соравына каршы җавабында К. Насыйри үзе болай дигән: «Мин хатын алмадым түгел, алдым, хәтта, икене алдым. Фәкать беренчесе илә мәхәббәтемез булмады, өлфәт[2] итә алмадык. Үзе аерылырга сорады да аердым. Бунысы яшь вакытымда иде. Аннан соң тагын бер хатын алдым. Бунысы илә яхшук мәхәббәтемез дә булды, ләкин минем язу хезмәтемә бик күп кимчелек китерә башлады. Бик күп хезмәтләрем аның мәхәббәтенә корбан булдылар. Язу вә башка хезмәтләремә хәләл килмәсен өчен бунысын үзем талак иттем, – диде»[3].

К. Насыйри гомере буе Казанда яши. Ул берничә мәртәбә Мәскәүгә, андагы агасы Габделхәй (1818–1890) янына, Ибраһим Арсланов (?–?) исемле бай белән Мәкәрҗә ярминкәсенә – Түбән Новгородка, имтихан тоту өчен Диния нәзарәтенә Уфага һәм кардәше Мөхәммәтбәдигъ Хөсәенов (1853–1929) белән Оренбургка бара[4]. Әмма һәр җәйдә диярлек туган авылы Югары Шырданга кайта торган була. Шул вакытларда, тирә-як авылларга чыгып, археологик, этнографик материаллар, риваятьләр, халык иҗаты туплау, кырларда төрле үләннәр җыйнау белән шөгыльләнә.

К. Насыйриның Казанда хосусый йорт-җире булмый. Бу хакта инде бераз сүз булды. Ул Руханилар семинариясендә укыткан вакытта аның чарлагында яши. 1865 елда Мөсә-

---

[1] Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) / М. Гайнуллин // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары) / Җав. ред. Ш. А. Рамазанов. – Казан: Таттосиздат, 1948. – Б. 13.

[2] *Өлфәт итә алмадык* – ияләшә алмадык.

[3] Әл-Хуҗаши Н. Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри илә мосахәбә / Н. әл-Хуҗаши // Шура. – 1912. – № 24. – Б. 747.

[4] Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) / М. Гайнуллин // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)... – Б. 11.

гыйть ямщик дигән кешенең Зөһрә исемле кызына өйләнгәч, кайнатасы йортында гомер итә башлый. Хатыны баладан вафат булганнан соң (1866) да берничә ел анда кала. 1872 елда Казанда Укытучылар мәктәбе ачылып, рус-татар башлангыч мәктәбендә укыта башлагач, Яңа Бистәдә Степанов йортында, 1873 елда Фукс урамындагы, аннан соң Шиһаб хәзрәт мәхәлләсендәге Захарьев урамындагы йортларда фатир алып тора[1]. 1879 елда Тихвин (хәзер – Тукай) урамында Госмановлар мәчетеннән берничә йорт аша яшәгәнлеге мәгълүм[2]. 1885 елда икенче гильдия сәүдәгәр Гайса хаҗи Мусин (1816–1887) йортында[3], 1890–1891 елларда Тихвин һәм Евангелистлар урамнары чатында печән үлчәве каршында Чуаш иле Хәсән йортында, 1891–1892 елларда бер кыш Захарьев урамы башындагы Сөләңгәр Камали йортында тора[4]. 1893 елның көзеннән башлап сәүдәгәр Сөләйман Аитов (1862–1922) карамагында булган агач өйдә[5], абзасы Габделхәйнең улы Габделмән Казанский (?–?) өендә (хәзерге Галиәсгар Камал урамында), Кызыл мәчет урамында Әптелмән йортының кечкенә бер бүлмәсендә[6], Екатерина урамындагы Ядгәр Шаһи (Ядгәр Ишимов) йортының өске катында, хәзерге Мәрҗани урамының Печән базарына таба урнашкан йортта һәм, үзенең бер

---

[1] Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле / Г. Рәхим // Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга / Ред. Һәйят. – Казан: ТССҖ дәүләт нәшр., 1922. – Б. 26–27, 29.

[2] Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле... – Б. 31.

[3] Элекке Поперечно-Сенная, хәзерге Париж Коммунасы урамы, 24 нче йорт.

[4] Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле... – Б. 29–30.

[5] Хәзерге Тукай урамында булган 45 нче ул йорт сакланмаган. Аның фотосы теркәлгән чыганак: Җәләй Л. Каюм Насыйри (1825–1902) / Л. Җәләй // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татгосиздат, 1945. – Б. VIII.

[6] Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)... – Б. 138.

хатыннан күренгәнчә, ниндидер Чыршы Габди һәм башкаларның йортларында гомер кичергәннән соң, 1899 елдан туганы Мөхәммәтбәдигъ мөәзин өенең[1] беренче катында яши башлый. Дөрес, ул анда 1885, 1892 елларда да торып алган була. Шунда 1902 елның 21 августында (3 сентябрендә) 77 яшендә вафат була. Аны соңгы юлга озатырга, ни кызганыч, кешеләр аз килә[2]. Мәрхүмнең җәсәде шәһәрнең Яңа Татар бистәсе зиратында дәфен кылына.

***

К. Насыйриның тормышы һәм эшчәнлеге белән кызыксына башлау Октябрь түнтәрелешенә кадәр үк башлана. Сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы Ш. С. Алкин (1893–1918 елдан соң) ниндидер бер авылда өй чормасындагы кәрзиндә галимнең әтисенә язган хатларын табып ала. Ул аларның бары тик сигезен генә алуын белдерә һәм шуларның икесен «Аң»[3] журналының 1912 елгы беренче санында бастырып чыгара[4]. Танылган тарихчы, филолог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Баттал (1880–1969) татар теле турында «Йолдыз» газетасының 1912 ел 11 октябрь санында «Телебез» дигән күләмле мәкалә бастыра[5]. Бу өлкәдә К. Насыйриның да эшчәнлеген югары бәһаләп, болай яза: «Үз арабыздан чыгып, үз телебезне тергезү нияте белән кулына каләм тоткан затларның иң олугсы Габделкаюм ән-Насыйри абзыйдыр... Бу җәһәттән

[1] Хәзерге Париж Коммунасы урамы, 35 нче йорт.

[2] Бу хакта тулырак: Бәхтияров В. Каюм абзый Насыйри турында кечек бер истәлек // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык // Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз. Р. Исламов. – Казан: Җыен, 2017. – Б. 514–522.

[3] *«Аң»* – Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәни (1883–1934) мөхәррирлегендә һәм наширлегендә 1912–1918 елларда Казанда татар телендә ике атнага бер чыккан әдәби, фәнни, сәяси һәм иҗтимагый рәсемле журнал. Барлыгы 123 саны дөнья күргән.

[4] Алкин Ш. Каюм Насыйри хатлары / Ш. Алкин // Аң. – 1912. – № 1. – Б. 14–15.

[5] Баттал Г. Телебез / Г. Баттал // Йолдыз. – 1912. – 11 окт.

руслар арасында Даль нинди урын тотса, Габделкаюм абзый да бездә шул урынны шөгыльләнәдер...». Шул ук вакытта ул галимгә һәм эшчәнлегенә тиешле дәрәҗәдә игътибар бирелмәвенә, көндәлек матбугатта аның исеме очрамавына борчылуын белдереп, шулай ди: «...Татар теленең атасы, гыйлем вә әдәб хадиме, безнең ише ялкау халыктан бик сирәк чыга торган бер тырыш вә эш сөючән кеше булган бу затны, ни өчендер, халкыбыз тәкъдир итә алмый. Әллә нинди гарәпләрне, персияннарны казып чыгарып, тәрҗемәи хәлләрен беренче сәхифәсеннән баскан «Шура»[1] мәҗмуагасы да Габделкаюм абзыйны игътибарга алмады...»

Шуннан соң аңа җавап рәвешендә булса кирәк, Ризаэтдин бине Фәхретдин (1859–1936) «Шура» журналының 1912 елгы егерме беренче санында «Габделкаюм Насыйри» дигән мәкалә урнаштыра[2]. Аерым алганда ул шулай дип яза: «Габделкаюм әфәнденең яшьлегендә, хәтта егетлек вакытларына ирештегендә улан хәлләре хакында мәгълүматымыз юк, соңгы хәлләре хакында хәбәремез аз. Бунын гасырына йитештек вә бунын сәламәт вакытында бер дәфга[3] Казан шәһәренә бардык исә дә күрешә алмадык». Аның хезмәтләрен нәшер итәргә тырышуы сәбәпле рәхмәт әйтеп язган бер хаты сакланган булуы, әмма тентү вакытында алынып, кире кайтарылмавына үкенеч белдерә.

Язмада шулай ук Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче Сөләйман Аитов (1862–1922) сөйләгәннәрен китереп, К. Насыйриның аның өендә түләүсез яшәп, улы һәм Тро-

---

[1] *«Шура»* – Оренбургта 1908–1917 елларда Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936) мөхәррирлегендә һәм алтын приискалары хуҗалары, танылган иганәчеләр һәм җәмәгать эшлеклеләре бертуган Мөхәммәтшакир (1857–1912) һәм Мөхәммәтзакир (Дәрдемәнд) (1859–1921) Мөхәммәтсадыйк уллары Рәмиевләр баширлегендә унбиш көнгә бер чыккан әдәби, фәнни һәм сәяси журнал. Барлыгы 240 саны дөнья күргән.

[2] [Фәхретдин Р.] Габделкаюм Насыйри // Шура. – 1912. – № 21. – Б. 641–645.

[3] *Бер дәфга* – бер тапкыр.

ицкидан Габделвәли Яушевның[1] улы янына тагын алты фәкыйрь баланы кушып укытуы турында мәгълүмат бирә.

Сәясәт эшлеклесе, журналист, нашир, педагог, тел галиме Әхмәтһади Максудиның (1868–1941) шул ук мәкаләдә кителгән истәлегеннән күренгәнчә, ул Кырымда Зынҗырлы мәдрәсәсендә эшләгән вакытта рус теле укытучысы Исмәгыйль Лиманов (?–?) Россиядәге әдипләр һәм галимнәрнең тәрҗемәи хәлләрен сорап ачык хат бастыра. Ә. Максуди Казанга кайткач, шул мәсьәлә буенча К. Насыйри янына махсус бара. Ләкин сөйләшүләр ул көткән нәтиҗәне бирми.

Язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе Фатих Кәриминең (1870–1937) хатирәсеннән аңлашылганча, аның К. Насыйри белән очрашуы бик кыска була. Ул Истамбулда исеме шөһрәт казанган бу затның Казанда алай ук билгеле булмавына гаҗәпләнүен белдерә.

Р. Фәхретдин К. Насыйриның исеме Төркиягә ирешеп хөрмәт белән искә алынуында җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, мәгърифәтче, педагог, нашир Исмәгыйль Гаспринский (1851–1914) һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист Гөлнар ханымның (Лебедева Ольга Сергеевна, 1854–?) ролен билгели.

Аннары журналда татар укымышлылары һәм зыялыларының әтрафлы мәкаләләре бастырыла. Нуретдин Ишаев (?–?) истәлегеннән күренгәнчә, алар – үзе һәм остазы Өчбүлә[2] авылының Фәйзрахман хәзрәт[3], К. Насыйри белән 1898 елның

---

[1] Габделвәли Яушев (1840–1906), Троицкидагы танылган сәүдәгәр, иганәче; җәмәгать эшлеклесе С. Аитовның хатыны Фатыйха Аитованың (1866–1943) әтисе.

[2] *Өчбүлә* – хәзер Башкортстан Республикасының Дүртөйле районындагы авыл.

[3] Фәйзрахман Әхмәтҗан улы Тупиев (1861–?), Өчбүлә авылы имамы, атаклы морзалар нәселеннән; ватандашлар сугышы вакытында Оренбургта фаҗигале рәвештә һәлак була.

Студент вакытымда 1983 елның июнь-июль айларында фольклор экспедициясендә бу авылда булып, заманында Фәйзрахман хәзрәт мәдрәсәсендә укыган Мөстәкыйм исемле бабайны күреп сөйләшергә туры килгән иде. – *Р. И.*

май урталарында Казанда, ул Сөләйман Аитов йортында яшәгән вакытта очрашалар[1]. Галим күңеле булып: «Казан халкы тәкъдир кылмаса[2] да, читтән килеп искә төшерүчеләр бар», – ди. Алар аңардан берникадәр китап та алалар.

Екатеринбургтан язган публицист һәм язучы Һади Таһири (?–?), К. Насыйриның туган-тумачалары турында мәгълүмат биреп, үзенең дә чыгышы белән Югары Шырданга күрше авылдан һәм галимгә кардәш булганлыгын белдерә[3].

Истәлеге басылганда Малмыж шәһәрендә яшәгән Мөхәммәткәмал Мозаффар (?–?)[4] 1896 елда Казанда К. Насыйри янына кереп, озак кына сөйләшеп утыруларын бәян итә. Аерым алганда, галимнең барлык энергиянең кояштан алынганлыгы турында аңлатуы аңарда зур кызыксыну уяткан. Ул шулай ук аның 1895 елның 24 нче декабрендә, 1896 елның 2 февралендә язган ике хаты, китаплары хакында хисап язуы саклануын белдерә[5]. Соңгылары истәлек ахырында тулысынча китерелгән.

Көнчыгыш телләре белгече Галимҗан Акчурин (1895–1933) үзенең мәкаләсендә Әхмәров[6], Терегуловларның[7] Ка-

---

[1] Ишаев Н. Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр / Н. Ишаев // Шура. – 1912. – № 22. – Б. 694.

[2] *Тәкъдир кылмаса* – бәяләмәсә, танымаса.

[3] Таһири Һ. Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр / Һ. Таһири // Шура. – 1912. – № 23. – Б. 719.

[4] Бу шәхес турында әлегә Р. Фәхретдиновның 1914 елның 12 мартында аның белән очрашып сөйләүшүе хакындагы мәгълүматы гына билгеле: Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар / Фәнни мөх. М. Госманов; төз.: Л. Байбулатова, Р. Йөзмөхәммәтов, А. Салахов, Р. Миңнуллин, И. Гыймадиев, С. Хафизова / Р. Фәхреддин. – Казан: Рухият, 2010. – Б. 350.

[5] Мозаффар Мөхәммәткәмал. Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр / М. Мозаффар // Шура. – 1912. – № 23. – Б. 719.

[6] *Әхмәров* – Шаһбазгәрәй Исмәгыйль улы Әхмәров (1853–1900), педагог һәм җәмәгать эшлеклесе. 1876–1900 елларда Татар укытучылар мәктәбендә рус теле укытучысы, 1881 елдан әлеге уку йортының директоры.

[7] *Терегулов* – Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов (1852–1921), педагог, ветеринария табибы.

зан укытучылар мәктәбендә К. Насыйри белән бергә эшләүләрен, истәлек язуларын сорап аларга мөрәҗәгать итәргә кирәклеген яза[1].

Н. әл-Хуҗаши үзенең истәлегендә[2] хәбәр иткәнчә, ул Казанда Габделгалләм мәдрәсәсендә укыган вакытта Татар укытучылар мәктәбендә белем алучы Фуат Туктаров[3], Габдерәүф Ниязбаев[4] белән бергә 1902 елның 9 гыйнварында К. Насыйри ри янына баралар. Ул аларга җиде йөз илле битлек «Мифтах әл-Коръән» («Коръәнгә ачкыч») дип аталган уникаль лексикографик хезмәтенең кульязмасын күрсәтә һәм шулай ди: «Буңа әле исем куйганым юк. Бунын илә Коръән Кәримнең һәр аятен вә һәр кәлимәсен табып булачак. Дөрест, бу хакта тәртибе зиба[5] илә Америка миссионеры тарафыннан тәртип ителгән «Нө-«Нөҗем әл-Коръән» исемле китаплар бар, фәкать анлар канәгатьләнерлек түгел». Автор бу китапның кем кулында калуы һәм басылу-басылмавы аңа мәгълүм булмавын искәртә. Бу хезмәт Казан университетының Фәнни китапханәсендә сакланып калган. Аның хакында язучы һәм галим М. Гали (1893–1952) К. Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган сессия материалларында басылган мәкаләсендә хәбәр итә[6].

Түнтәр авылы мулласы, дин белгече һәм эшлеклесе, педагог, җәдитчелек хәрәкәте тарафдары Мөхәммәтнәҗип Түнтәри[7]

---

[1] Акчурин Г. [Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүмат] / Г. Акчурин // Шура. – 1912. – № 23. – 3 т.б.

[2] Әл-Хуҗаши Н. Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри илә мөсахәбә (хатирә дәфтәремнән) / Н. әл-Хуҗаши // Шура. – 1912. – № 24. – Б. 745–748.

[3] Фуат (Мәхмүтфуат) Фәсах улы Туктаров (1880–1938), җәмәгать эшлеклесе һәм сәяси эшлекле; Татар укытучылар мәктәбен 1904 елда тәмамлый.

[4] Габдерәүф Хәким улы Ниязбаев (1881–1920), драматург.

[5] *Тәртибе зиба* – матур рәвешле.

[6] Гали М. Каюм Насыйриның кульязма мирасы / М. Гали // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)... – Б. 120.

[7] Мөхәммәтнәҗип Шәмсетдин улы Шәмсетдинов.

(1862–1930) үзенең зур булмаган истәлегендә К. Насыйри белән берничә тапкыр очрашуы турында яза[1]. Ул аңарга шәкертләр ирексездән укысын өчен кайбер әсәрләрен басылган табагы белән бүлмә диварларына элеп куюы турында әйтүен, мәдрәсәләрдәге кайбер тәртипсезлекләрдән зарланганын искә ала.

Булачак мәгърифәтче шагыйрь Гарифулла Чокрый (Гарифулла Мөхәммәтгали улы Киеков, 1861–1918) 1879 елда, әтисен[2] өченче мәртәбә хаҗ сәфәренә озата килгәндә, Казанда К. Насыйри белән күрешүен яза[3]. Г. Чокрый үзенең дә горрәлек лек язуын, аны Бөре өязенең Кочмаш авылы имамы Гайнулла мулланың Казанга алып китеп югалтуын әйтә. Галим аны күргән булуы турында шулай дигән: «Беләм, күргәнем бар, Сезнең ул иҗтиһадыңызга бик тәхсин иттем. Мәгәр дибәҗәләп[4] вә дибәҗәсене гарәпчәләп мәшәкатьләнгәнсез икән, «Төрке барның күрке бар» дигәндәй, бән үзем саф төрки телен яратам».

Адресы Кукмара станциясе һәм Казан губернасының Пычак карьясе[5] дип күрсәтелгән Мөхәммәтхәнәфи Мозаффар (?–?) үзенең истәлегендә[6] әүвәл әтисе Мөхәммәтҗанның Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә укыган вакытында К. Насыйри белән очрашулары турында сөйләгәннәрен яза. Күренгәнчә, ул русча дәресләр алу бәрабәренә галимнең хезмәтләрен күчереп яза торган булган. Бер янгын вакытында күп кенә язмалары юкка чыгу фактын да китерә, әмма казаның кайсы елда һәм кайда булганлыгын күрсәтми. Башка чыганаклардан күренгәнчә,

---

[1] Түнтәри М. Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләрем / М. Түнтәри // Шура. – 1913. – № 3. – Б. 72.

[2] Гали Чокрый (Мөхәммәтгали Габдессалих улы Киеков, 1826–1889), шагыйрь, дин эшлеклесе.

[3] Чокрый Гарифулла бине Гали. Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. – 1913. – № 5. – Б. 141–142.

[4] *Дибәҗәләп* – кереш сүз белән.

[5] *Пычак карьясе* – хәзер Татарстан Республикасының Кукмара районындагы авыл.

[6] Мозаффар Мөхәммәтхәнәфи. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында / Мөхәммәтхәнәфи Мозаффар // Шура. – 1913. – № 6. – Б. 172–175.

фаҗига ул Гайса хаҗи Мусин йортында яшәгәндә, 1885 елда, булган. Автор К. Насыйри хезмәтләреннән күчерелгән кырык дүрт бит язманың әтисе кулында булганлыгын белдерә.

Бу уңайдан шуны да әйтергә кирәк: хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университеты Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «Гөлзар вә чәмәнзар» кулъязмасының якяклары әнә шул янгын вакытында утта өтелгән бер нөсхәсе саклана.

Мөхәммәтнәҗип бине Шәрәфетдин әл-Кустрамави (?–1932) үзенең истәлегендә К. Насыйриның шәкерт вакытында чыгышы белән Кострома шәһәреннән булган Шәмсетдин бине мулла Шәмсуар бине Әмирдә (?–1849) белем алганлыгын, остазы вафатыннан соң аның каберенә язулы такта куйганын бәян итә. Аннары, галим эшчәнлеген яктыртып, хезмәтләренә, календарьларына шактый тәфсилле анализ ясый[1].

Кәчимир[2] авылыннан булган дин эшлеклесе һәм публицист Габдулла бине Таҗетдин хатирәсеннән[3] күренгәнчә, ул Күл буе мәдрәсәсендә[4] укыган вакытында берничә шәкерт белән К. Насыйридан русча дәресләр алырга йөргән. Автор, авылына кайтып мулла булгач та, Казанга килгән вакытларында һәрвакыт аның янына кереп хәл-әхвал белешкән. Бервакыт галим аңа хәдисләр, хәкимнәрнең сүзләре язылган, сигез кисәктән гыйбарәт булган «Тәзкирә» кулъязмасын бүләк иткән. Журнал редакциясе дә аның белән кызыксынган һәм укучылар игътибарына тәкъдим итәргә кирәклеген белдергән.

---

[1] Әл-Кустрамави Мөхәммәтнәҗип бине Шәрәфетдин. Габделкаюм ән-Насыйри хәзрәтләре тәрҗемәи хәленә гаид // Шура. – 1913. – № 8. – Б. 233–237.

[2] *Кәчимир* – бу авыл хәзерге Кукмара районында.

[3] Әл-Кәчимири Габдулла бине Таҗетдин. Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. – 1913. – № 10. – Б. 292–293.

[4] Мәдрәсә Казанда 1770 елда Апанаев мәчете каршында ачылып, «Апанаев», «Күл буе» һәм соңгы мөдәррисләреннән берсе Касыйм (Мөхәммәткасыйм) Габделгаллләм улы Салихи (Салихов) (1871–1954) исеме белән «Касыймия» дип атала. 1918 елда ябыла.

Гомумән, бу истәлек-хатирәләр галимнең шәхесен объектив чагылдырган иң ышанычлы чыганак булып тора.

Совет хакимияте вакытында филолог, педагог Мөхетдин Корбангалиевнең (1873–1941)[1], журналист Вафа Бәхтияровның (1881–1960)[2], туганы, ягъни Мөхәммәтбәдигъ мөәзин улы Әхмәт Хөсәеновның (1895–1944)[3], шагыйрь Миргазиз Укмасиның (1884–1948)[4] истәлекләре дөнья күрә.

К. Насыйрины искә алу чаралары, төрле юбилейларын үткәрү эзлекле һәм дәвамлы башкарылып килә. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты Гыйльми үзәге, К. Насыйриның вафатына 20 ел тулуга туры китереп, 1922 елның 2 сентябрендә искә алу көне үткәрергә карар итә. Аны оештыру өчен рәисе Г. Ибраһимов (1887–1938) һәм әгъзалары С. Атнагулов (1893–1937), Г. Гобәйдуллин (1887–1938) булган өч кешелек комиссия төзелә һәм галим хакында мәҗмуга әзерләү чарасына керешелә. К. Насыйрины белгән кешеләргә мөрәҗәгать ителеп, кулларында материаллар, язулар, хатирәләр, китаплар, рәсемнәр һәм башка әйберләр булган кешеләрнең ярдәм итүе үтенелә һәм элемтә өчен адрес күрсәтелә[5]. Нәтиҗәдә, мәҗмуга төзелеп, шул ук елда нәшер ителә[6].

Татарстан Мәгариф халык комиссариаты Гыйльми үзәге татар редакциясе коллегиясе, 1925 ел 10 февраль утырышында К. Насыйриның тууына йөз ел тулуны билгеләп үтү мәсьә-

---

[1] Корбангалиев М. Каюм Насыйри турында истәлекләр / М. Корбангалиев // Кызыл Татарстан. – 1925. – 15 февр.

[2] Бәхтияров В. Каюм абзый Насыйри турында кечек бер истәлек / В. Бәхтияров // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык... – Б. 514–518.

[3] Хөсәенов Ә. Каюм Насыйрый турында кайбер истәлекләр / Ә. Хөсәенов // Совет әдәбияты. – 1940. – № 7. – Б. 80–82.

[4] Укмаси М. Каюм абзый Насыйри (Истәлек) / М. Укмаси // Совет әдәбияты. – 1945. – № 2. – Б. 61–62.

[5] Каюм Насыйрины искә төшерү // Татарстан. – 1922. – 19 июнь.

[6] Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга / Ред. Һәйят. – Казан: ТССҖ дәүләт нәшр., 1922. – 160 б.

ләсен тикшереп, шундый карар кабул итә: «1) Йөз ел тулган көнне К. Насыйриның шәхесе белән киң катлауны таныштыру, аның ролен ачыклау һәм хезмәтләрен җентекләү максатында зур ачык җыелыш уздырырга; 2) Журналистика Институтында К. Насыйри исемендәге стипендия булдыру хакында Татарстан Мәгариф халык комиссариаты коллегиясенә юллама белән мөрәҗәгать итәргә; 3) 4 Евангелистлар урамын К. Насыйри исеменә алыштырырга; 4) Бу көнне билгеләп үтү өчен тиешле оешмаларга мөрәҗәгать итәргә.

Йөз ел тулу көнен билгеләп үтү өчен Комиссия төзүне Академүзәккә йөкләргә. Программаны нигездә кабул итәргә, аны детальләштерүне һәм үткәрүне шул ук комиссиягә тапшырырга»[1].

К. Насыйриның тууына йөз ел тулу уңаеннан матбугатта аның тәрҗемәи хәленә карата кызыклы гына мәгълүмат бастырыла. Аерым алганда, аның 1824 елда түгел, ә 1825 елда туганлыгын дәлилли торган материаллар табылуы хакында языла[2]. Шул ук вакытта галимнең юбилее зурлап үткәреләчәге дә хәбәр ителә.

1925 елның 15 февралендә кичке сәгать 7 дә Дәүләт татар театрында К. Насыйриның тууына йөз ел тулуга багышлап, керү ирекле булган зур җыелыш үткәреләчәге хакында «Кызыл Татарстан» газетасында игълан бастырыла. Анда Г. Ибраһимовның «Каюм Насыйриның тарихи роле», М. Парсинның «Насыйриның биографиясе», М. Корбангалиевнең (1873–1841) «Насыйриның имля, әдәби тел турында хезмәтләре» дигән темаларга докладлары, әлеге чара уңаеннан Татарстан Җөмһүрияте хөкүмәтенең ничек олылавы турындагы эшләре тыңланылачагы белдерелә[3].

---

[1] Татарстан Республикасы Милли архивы, Р-3682 ф., 1 тасв., 694 эш, 22 кәг. икенче ягы.

[2] Каюм Насыйриның туганына йөз ел тула // Кызыл Татарстан. – 1925. – 8 февр.

[3] Каюм Насыйриның тууына йөз ел тулу уңае белән зур җыелыш! // Кызыл Татарстан. – 1925. – 15 февр.

Дөрестән дә, ул җыелыш үткәрелә[1]. Анда белдерүдә күрсәтелгән чыгыш ясаучылардан тыш янә Ф. Әмирхан, Г. Рәхим (1892–1943), Ә. Максуди, З. Нуркин (1888–1966), Хәйретдин Вәлиев (1893–1969), Ш. Әхмәдиев (1888–1930) тә катнаша. Чараны Г. Ибраһимов ача һәм алып бара. Ш. Әхмәдиев, Татарстан Җөмһүрияте хөкүмәте исеменнән чыгыш ясап, К. Насыйри исемен мәңгеләштерү юнәлешендә түбәндәге эшләр башкарырга карар бирелгәнне хәбәр итә: 1) Мәскәүдә Журналистлар институтында Насыйри исемендәге стипендия билгеләргә, 2) татар тәгълим-тәрбия техникумын Насыйри исеме белән атарга, 3) Казандагы Евангелистлар һәм Яңа Бистәдә Большой Симбирский урамнарын Насыйри урамы дип атарга, 4) Насыйри әсәрләрен сайлап бастырырга.

Аннан соң Ш. Әхмәдиев Татарстан Җөмһүрияте Үзәк башкарма комитеты рәисе Ш. Шәймәрданов, Татарстан Җөмһүрияте Халык комиссарлары Советы рәисе Х. Габидуллин (1897–1940) имзалаган котлау хатын укып ишеттерә.

К. Насыйриның тууына йөз ел тулу уңаеннан үткәрелгән җыелыш хакында белешмә Автономияле Татар Совет Социалистик Республикасы Мәгариф халык комиссариаты Коллегиясенең 1925 елның 13 мартында булган ачык утырышында Гыйльми үзәкнең 1924/25 еллардагы эшчәнлеге хакында аның рәисе Г. Ибраһимов тарафыннан укылган докладта да чагылыш таба[2].

АТССР Мәгариф халык комиссариаты Коллегиясенең 1925 ел 24 февраль карары нигезендә Татар педагогия техникумына К. Насыйри исеме бирелә[3].

Академүзәк Коллегиясенең 1925 ел 26 март утырышында, Автономияле Татар Совет Социалистик Республикасы Халык

---

[1] Латыйф Г. Каюм Насыйрины искә төшерү турында зур җыелыш // Кызыл Татарстан. – 1925. – 18 февр.

[2] Татарстан Республикасы Милли архивы, Р-3682 ф., 1 тасв., 628 эш, 77 кәг. икенче ягы.

[3] Татарстан Республикасы Милли архивы, Р-3682 ф., 1 тасв., 628 эш, 69 кәг.

комиссарлары Советы күрсәтмәсе буенча, К. Насыйриның тууына 100 ел тулу уңае белән аның мәҗмугасын төзү мәсьәләсе тикшерелә. Нәтиҗәдә эшне башкару Г. Ибраһимовка йөкләнелә һәм ул ун табак күләмгә исәпләнелә. Эчтәлеген галимнең тууына йөз ел тулуга багышланган материаллар, аның басылмаган хезмәтләре хакында Г. Гобәйдуллинның мәкаләсе тәшкил итәргә тиеш була[1]. Бу карар хакында «Безнең юл» журналының 1925 елгы 5 санында да хәбәр ителә[2]. Әйтергә кирәк, ул мәҗмуга 1926 елда басылып чыга[3].

Бөек Ватан сугышы барган 1945 елның мартында К. Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган юбилей чаралары киң күләмдә үткәрелә. Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институтында 18–19 мартта, Мәскәүдә 26 мартта гыйльми сессия уздырыла. Анда әдәбиятчылар М. Гайнуллин, М. Гали, Ж. Вәзиева (1907–1989), тел галимнәре Н. К. Дмитриев (1898–1954), Ш. Рамазанов (1887–1948), В. Хангильдин (1891–1971), Р. А. Хәкимова (1902–1952), тарихчылар Н. И. Воробьёв (1894–1967), Х. Гыймади (1912–1961), фольклорчы Х. Ярми (1904–1981), педагог В. М. Горохов (1891–1960), табиб Ф. Мөхәммәдьяров (1883–1950) галимнең тормышын һәм эшчәнлеген киң яктырткан докладлар укыйлар. Аның материаллары татар[4] һәм рус[5] телләрендә аерым җыентыклар итеп нәшер ителә. Анда К. Насыйриның авылдашлары Гыйбадулла Төхфәтуллин (1871–?), Талип Гайсин (1875–?), Гыйльман Ногманов (1885–?),

---

[1] Татарстан Республикасы Милли архивы, Р-3682 ф., 1 тасв., 694 эш, 13 кәг.

[2] Гыйльми Үзәктә // Безнең юл. – 1925. – № 5. – Б. 218.

[3] Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга / Г. Рәхим карамагында. – Казан: Татар. дәүләт нәшр. басмасы, 1926. – 135 б.

[4] Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары) / Җав. ред. Ш. А. Рамазанов. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 146 б.

[5] Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвященных 120-летию со дня рождения) / Отв. ред. Н. И. Воробьев. – Казань: Татгосиздат, 1948. – 135 с.

Мәсхәпҗамал Ибәтуллина (1885–?), Гатаулла Дусаев (1887–?), әнисе ягыннан туганы Габделбарый Насыйров (1881–?), дин эшлеклеләре Зыя (Мөхәммәтзыя) Бәхтияров (1877–1974), Хатыйп Алишевның (?–?) галим турында кызыклы истәлекләре дә урын алган[1]. Бу юбилей уңае белән фронт татар газеталарының берсендә махсус мәкалә бастырыла[2].

Галимнең 125 еллыгы да матбугатта мәкаләләр белән билгеләнеп үтелә[3]. Әдәбиятчы М. Гали Казан дәүләт университеты китапханәсендә К. Насыйриның аңарчы мәгълүм булмаган «Хитабате лиәһли Казан» («Казан халкына мөрәҗәгать») дигән 150 бит күләмендәге кулъязма хезмәтен табып ала һәм аның аерым үрнәкләре белән укучыларны таныштыра[4]. «Бу әсәр, – диелә кереш өлештә, – ул вакыттагы Казан татарларының тормыш-көнкүрешләренә, гадәт-йолаларына һәм тәрбия мәсьәләренә карата К. Насыйриның үзенчәлекле тәнкыйть карашларын бик ачык чагылдыра»[5].

1975 елда К. Насыйриның тууына 150 ел тулу юбилее тантаналы рәвештә зурлап үткәрелә. 11–12 февраль көннәрендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан дәүләт университеты һәм Казан дәүләт педагогия институты белән берлектә Республика җитәкчелеге, галимнәр, киң җәмәгатьчелек катнашында университетның Актлар залында фәнни конференция уздырыла. К. Насыйри яшәгән чорны, аның фәлсәфи карашларын, татар телен һәм әдәбиятын үстерүгә керткән өлешен, тарих, археология, этнография, фольклор өлкәсендәге фән-

---

[1] Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)... – Б. 137–141.

[2] Каюм Насыйриның тууына 120 ел // Ватан намусы өчен. – 1945. – 11 апр.

[3] Гайнуллин М. Бөек мәгърифәтче һәм патриот / М. Гайнуллин // Совет әдәбияты. – 1950. – № 2. – Б. 67–73.

[4] Каюм Насыйриның басылмаган кулъязмасы // Совет әдәбияты. – 1950. – № 2. – Б. 74–78.

[5] Каюм Насыйриның басылмаган кулъязмасы… – Б. 74.

ни казанышларын, педагогик эшчәнлеген, Республика Дәүләт музеенда саклана торган фондын яктырткан егреме алты доклад тыңлана. К. Насыйриның кумык мәгърифәтчесе Әбусуфьян Акаевның (1872–1931) иҗтимагый-педагогик эшчәнлегенә бәрәкәтле тәэсире турында әдәбият галиме С. Х. Акбиев (1938–2004) чыгышы аеруча зур кызыксыну уята. Конференция материаллары аерым җыентык итеп бастырыла[1].

13 февральдә Татар Дәүләт академия театры бинасында тантаналы җыелыш була, сәнгать осталары зур концерт программасы белән чыгыш ясый.

Икенче көнне К. Насыйриның туган ягында – Олы Ачасыр авылы Мәдәният йортында шулай ук фәнни конференция уздырыла, Яшел Үзән шәһәренең сәнгать коллективы концерт куя.

К. Насыйриның тууына 170 ел тулу уңаеннан Казан дәүләт педагогия институтында «Каюм Насыйри һәм хәзерге педагогика» дигән темага укулар уздырыла[2].

2011 елның 2 февралендә Таарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре, төрле фәнни институтлар һәм югары уку йортлары галимнәре, язучылар, музей хезмәткәрләре катнашында К. Насыйриның Казандагы музеенда «Каюм Насыйри мирасын саклау һәм аны киләчәк буыннарга тапшыру проблемалары», 2013 елның 6 февралендә шунда ук «Каюм Насыйри мирасы хәзерге вакыттагы белем бирү процессында һәм музей киңлегендә» дигән Түгәрәк өстәл уздырыла.

К. Насыйриның тууына 190 ел, казакъ мәгърифәтчесе, шагыйрь Абай Конанбаевның (1845–1904) тууына 170 ел тулу уңае белән 2015 елның 26–27 февраль көннәрендә Казакъстан Республикасы башкаласы Астана шәһәрендә һәм мәркәзебез Казанда «Төрки дөнья мәгърифәтчеләренең иҗади мирасы»

---

[1] Выдающийся прсветитель-демократ Каюм Насыри / Отв. ред. Я. Г. Абдуллин. – Казань, 1976. – 216 с.

[2] К. Насыйрига багышлап // Казан утлары. – 1995. – № 4. – Б. 191.

дигән Халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрелә. Аның материаллары рус, татар һәм казакъ телләрендә нәшер ителә[1]. Әлеге юбилейга багышлап Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты тарафыннан «Урта һәм югары белем бирү системасында татар телендә укыту: тарих, хәзерге заман һәм перспектива» дигән Төбәкара фәнни-гамәли конференция[2] уздырылды.

2022 елның 24–25 февралендә Казанның К. Насыйри исемендәге 80 нче гомуми урта белем бирү мәктәбендә Төбәкара[3], 2023 елның 16–17 февралендә – II[4], 2024 елның 27–28 февралендә – III «Насыйри укулары» – «Насыровские чтения» дигән Халыкара фәнни-гамәли конференцияләре үткә-

[1] Творческое наследие просветителей тюркского мира: материалы Междунар. науч.-практ. конф., посвящ. 190-летию со дня рожд. К. Насыри и 170-летию со дня рожд. А. Кунанбаева (гг. Астана–Казань, 26–27 февраля 2015 г.) / Под общей ред. Р. Р. Замалетдинова. – Казань: Отечество, 2015. – 312 с. = Төрки дөнья мәгърифәтчеләренең иҗади мирасы: К. Насыйриның тууына 190 һәм А. Кунанбаевның тууына 170 ел тулуга багышл. Халыкара фәнни-гамәли конф. материаллары (Астана-Казан шш., 2015 ел, 26–27 февраль). – Казан: Отечество, 2015. – 312 б. = Түік әлемі ағартушыларының шығармашылық мұрасы: К. Насыридің 190-жылдығы мен Абайдың 170-жылдығына арналған Халықаралық ғылыми-практ. конф. материалдары (Астана-Казан ққ., 26–27 акпан 2015 ж.). – Қазан: Отечество, 2015. – 312 б.

[2] Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы: материалы Рег. науч.-практ. конф., посвящ. 190-летию со дня рожд. К. Насыри / Науч. ред.: М. М. Гибатдинов; сост.: Л. Р. Муртазина, Р. Р. Абызова. – Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 184 с.

[3] Насыйри укулары – Насыровские чтения: сб. материалов I Межрег. науч.-практ. конф. с междунар. участием (24–25 февраля 2022 г.) / Науч. ред. С. Д. Бородина; сост. А. Р. Мансурова; отв. за вып. Р. М. Мансуров. – Казань, 2022. – 244 с.

[4] Сборник материалов II Международной научно-практической конференции «Насыйри укулары» – «Насыровские чтения» (г. Казань, 16–17 февраля 2023 г.). – Казань: Новая Казань, 2023. – 94 с.

релде. 2022 елның 4 мартында Татарстан Республикасының Яшел Үзән шәһәрендә К. Насыйри исемендәге XX Халыкара яшүсмерләр фәнни-гамәли конференциясе уздырыла[1].

2023 елның 13 февралендә Казан (Идел буе) федераль университетының М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты каршындагы К. Насыйри үзәгендә «Каюм Насыйри: шәхес, галим, остаз» дигән коворкинг үткәрелә.

2024 елның 14 февралендә К. Насыйриның Казандагы музеенда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Милли музее җитәкчелеге вәкилләре, галимнәр, дин әһелләре һәм киң җәмәгатьчелек катнашында «Каюм Насыйри: мирасын музей киңлегендә актуальләштерү» дигән темага Түгәрәк өстәл була.

Шул ук елның 25 апрелендә Татарстан Фәннәр академиясе М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Энциклопедия үзәге тарафыннан киң җәмәгатьчелек катнашында «Каюм Насыйри» персональ энциклопедиясенең текст һәм иллюстрацияләр контентлары икърар ителешенең фәнни-методик үзенчәлекләре» темасына Түгәрәк өстәл үткәрелә.

Әйтергә кирәк, мондый фәнни-мәдәни чаралар шулай ук К. Насыйриның туган авылында, Республиканың башка төбәкләрендә даими рәвештә уздырыла.

Хәзерге вакытта Казанда К. Насыйри музее бар. Ул галимнең туганы Мөхәммәтбәдигъ мөәзин йортында урнашкан. Дөрес, чынлыкта булган бина 1970 елда янып, тулысынча юкка чыга. 1980 елда эшләнгән проект буенча ул фәнни нигездә реконструкцияләнә. Кызганыч ки, анысы да 1991 елда шундый ук аянычлы язмышка дучар була. Әмма ул янә торгызыла һәм 2002 елның 2 февралендә рәсми рә-

[1] XX Международная молодежная научно-практическая конференция имени Каюма Насыри: материалы конф. (4 марта 2022 г., г. Зеленодольск / Под общей ред.: А. Х. Ашраповой, Л. Х. Шаяхметовой. – Казань: К(П)ФУ, 2022. – 287 с.

вештә ачыла[1]. Музей комплексының фәнни концепциясе авторы һәм сәнгать проекты автордашы – Раушания Хөснетдинова. Ул шулай ук 1996–2013 елларда аның беренче директоры да була. Аннары бу вазыйфаны филология фәннәре кандидаты Рушания Шәфигуллина дәвам иттерә (2008–2023 елларда), музейның хәзерге директоры – Кадрия Хәлимова (2023 елдан).

Татарстан Республикасының Яшел Үзән районындагы Олы Ачасыр авылында Каюм Насыйри исемендәге архитектура һәм этнография комплексы 1992 елның 1 гыйнварында нигезләнеп, 1997 елның 1 мартында рәсми рәвештә ачыла[2]. Шунысын да әйтергә кирәк, музей бинасы булачак йортны Габделгани Минзарипов (1901–1986) дигән кеше К. Насыйри туганының Кече Шырданда яшәүче килененнән сатып алып, бирегә күчереп салган икән[3].

ТАССР Халык мәгарифе министрлыгы коллегиясе һәм РСФСР Педагогия җәмгыятенең Татарстан бүлеге президиумы 1988 елда Каюм Насыйри премиясе булдыру турында карар кабул итә[4].

Казанның 80 нче татар-рус гомуми белем бирү мәктәбенә 2021 елда Каюм Насыйри исеме бирелә.

---

[1] Бу хакта тулырак: Хөснетдинова Р. Андыйлар табигатьтә сирәк очрый / Р. Хөснетдинова // Казан утлары. – 1998. – № 4. – Б. 142–143; Насыри Каюма музей // Татарская энциклопедия: В 6 т. / Гл. ред. М. Х. Хасанов; отв. ред. Г.С. Сабирзянов. – Казань: Институт энцикл. АН РТ, 2008. – Т. 4: М–П. – С. 371–372.

[2] Бу хакта тулырак: Насыри Каюма имени архитектурно-этнографический комплекс // Татарская энциклопедия: В 6 т. / Гл. ред. М. Х. Хасанов; отв. ред. Г. С. Сабирзянов. – Казань: Ин-т энцикл. АН РТ, 2008. – Т. 4: М–П. – С. 371.

[3] Абзалина Р. Изге әманәт: Каюм Насыйри музеена 25 ел / Р. Абзалина // Мәдәни җомга. – 2022. – 30 дек.

[4] Каюм Насыйри исемендәге премия // Казан утлары. – 1988. – № 10. – Б. 190–191.

Каюм Насыйриның исеме төрле телләрдәге энциклопедияләргә, гомуми белем бирү мәктәпләренең дәреслекләренә кертелә.

Совет чорында К. Насыйриның тормыш юлы һәм мирасын өйрәнүгә зур өлеш кертүчеләрнең берсе, һичшиксез, әдәбиятчы М. Гайнуллин була. Ул күп санлы мәкаләләр белән бергә татар һәм рус телләрендә махсус монографияләр бастыра[1].

К. Насыйриның тел белеме, матур әдәбият, тарихи, фәнни темага караган материалларының, дәреслекләренең, календарьларының, аның яки үзенә килгән төрле хатларның төп нөсхәләре хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университеты Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана. Алар тел галиме Мостафа Ногман (1912–1976) тарафыннан фәнни яктан тикшерелеп, тасвирламасы аерым җыентык итеп бастырыла[2]. Анда шулай ук әдип-галимнең татар балаларын русча укыту өчен «Игъламнамә»се, «Хитабате лиәһли Казан» («Казан халкына мөрәҗәгать»), «Мифтах әл-Коръән» («Коръәнгә ачкыч»), Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы итеп сайланганлыгы турында Диплом, хисап документлары, Диния нәзарәте мәхкә-

---

[1] Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тууына 120 ел тулу уңае белән). – Казан: Татгосиздат, 1945. – 112 б.; *Аныкы ук.* Каюм Насыри: Его научная и просветительская деятельность / М. Гайнулин. – Казань: Татгосиздат, 1945. – 84 с.; *Аныкы ук.* Каюм Насыров и просветительская деятельность среди татар / М. Гайнуллин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1955. – 96 с.; *Аныкы ук.* Каюм Насыйри. Тормыш һәм иҗат юлы. Тууына 150 ел тулу уңае белән / М. Х. Гайнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 35 б.; *Аныкы ук.* Каюм Насыри: Очерк жизни и творчества / М. Гайнуллин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – 48 с.

[2] Ногман М. Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. III чыг. Каюм Насыйри кулъязмалары / Җав. ред. Ә. Г. Кәримуллин / М. Ногман. – Казан, 1958. – 49 б.

мәсенә бертуган Габделхәй, Габделкаюм, Габделгани, Габделкави тарафыннан язылган гариза, дәгъватнамәләр (чакырулар) дә бар[1].

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә К. Насыйриның аерым фонды тупланган. Ул йөз дә унбер саклау берәмлегеннән гыйбарәт[2]. Алар арасында галимнең паспорты (ул Мөхәммәтбәдигъ мөәзин улы Әхмәт Хөсәеновның (1895–1944) хатыны Хәдичә тарафыннан тапшырылган), кайбер басылган һәм басылмаган хезмәтләренең үзе рус телендә төзегән исемлеге, ул язган хатлар да саклана.

Татарстан Республикасының хәзерге Милли музеенда да К. Насыйриның махсус фонды бар. Анда галимнең үзе исән вакытта нәшер ителгән китапларын, астрономик глобусын, 1880 елларда бастырылган шәҗәрәсен һәм башка материалларны күрергә мөмкин[3].

К. Насыйриның татар тел белеме[4], педагогика[5] өлкәсендәге хезмәтләре һәм «Фәвакиһел-җөләса» әсәре әдәбият белеме

---

[1] Бу хакта тулырак кара: Каюм Насыйриның кульязма мирасы / М. Гали // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)... – Б. 119–130.

[2] Әхмәтҗанов М. И. Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече / М. Әхмәтҗанов. – Казан, 2005. – Б. 26–29.

[3] Багаутдинова Д. Б. Фонд Каюма Насыри в Государственном музее ТАССР / Д. Б. Багаутдинова // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри... – С. 208–211.

[4] Насырова Г.Г. Деятельность Каюма Насыри в области татарского языкознания: Автореф. дис… канд. филол. наук / Г. Г. Насырова; КГУ им. В.И. Ульянова-Ленина. – Казань, 2002. – 24 с.; Едиханов И. Ж. Лексико-стилистические особенности языка этико-дидактических и философских татарских текстов и их переводов на русский язык (на материале произведений К. Насыри, Ш. Марджани): Автореф. дис. ... канд. филол. наук / И. Ж. Едиханов; КГУ им. В. И. Ульянова-Ленина. – Казань, 2009. – 26 с.

[5] Фахрутдинов Р. З. Естественно-математическое образование в педагогическом наследии Каюма Насыри: Автореф. дис. … канд. пед. наук / Р. З. Фахрутдинов. – Казань, 2002. – 25 с.

нигезендә[1] өйрәнелеп, дүрт кандидатлык диссертациясе яклана, галимнең лексикографик эшчәнлеге хакында махсус монография нәшер ителә[2].

Совет хакимияте чорында К. Насыйриның «Сайланма әсәрләр»е 1945, 1953, 1956 елларда бастырыла[3], 1974–1975 елларда ике том итеп нәшер ителә[4]. 2003–2006 елларда К. Насыйри «Сайланма әсәрләр»енең дүрт томлыгы басылып чыга. Аның беренче, икенче, дүртенче томнарын әдәбиятчы М. Гайнетдинов (1927–2016)[5], ә өченче томын фольклорчы Х. Мәхмүтов (1933–2021)[6] төзи. Галимнең әсәрләре, хезмәтләре төрле телләрдә аерым китаплар булып та дөнья күрә.

---

[1] Шайдаева Л. Н. «Фаваких аль-джуласа» Каюма Насыри: проблематика и художественные особенности: Автореф. дис… канд. филол. наук / Л. Н. Шайдаева; ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. – Казань, 2010. – 26 с.

[2] Батыршина Г. Г. Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге / Г. Г. Батыршина. – Казан: КДАТУ нәшр., 2007. – 171 б.

[3] Мәсәлән: Насыйри К. Сайланма әсәрләр / М. Гайнуллин ред. – Казан: Татгосиздат, 1945. – 188 б.; Насыйри К. Сайланма әсәрләр / М. Гайнуллин ред. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 419 б.; Насыйри К. Сайланма әсәрләр / М. Гайнуллин ред. – Казан: Таткнигосиздат, 1956. – 2 басма. – 418 б.

[4] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда / К. Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 1 т. – 340 б.; Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 2 т. – 318 б.

[5] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда / Төз., гарәп график. сакланган текст. гамәлдәге язуга күч. М. Гайнетдин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 1 т. – 368 б.; Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда / Төз., гарәп график. сакланган текст. гамәлдәге язуга күч. М. Гайнетдин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 2 т. – 400 б.; Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда / Төз., гарәп график. сакланган текст. гамәлдәге язуга күч. М. Гайнетдин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 4 т. – 400 б.

[6] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда / Төз., гарәп график. сакланган текст. гамәлдәге язуга күч. Х. Мәхмүтов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 3 т. – 384 б.

Үзенчәлекле шундый бер фактны да әйтеп үтү урынлы булыр: К. Насыйриның латин графикасында басылган китаплары табылмады.

Галимнең Казан (Идел буе) федераль университеты Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең Шәрык бүлекчәсендә кулъязмада саклана торган «Мифтах әл-Коръән» («Коръәнгә ачкыч») дигән уникаль лексикографик хезмәте философия фәннәре кандидаты А. Хәйретдинов тарафыннан әзерләнеп, филология фәннәре кандидаты Р. Шәфигуллинаның кереш мәкаләсе белән ике томда нәшер ителә[1]. Ул – мөселман дөньясында Коръән Кәримнең беренче белешмәлеге-конкордансы булып тора.

К. Насыйриның хезмәтләре тематик яктан әдәбиятка (тәрҗемә әсәрләр), телгә (грамматика китаплары, сүзлекләр, үзөйрәткечләр), әдәбият һәм тел гыйлеменә, тарихка, геометриягә, дингә, этнографиягә, археологиягә, дәреслекләргә, әхлак-тәрбиягә, календарьлар төзүгә, математикага, химиягә, географиягә, ботаникага, медицинага, зәркән эшләренә, табигать белеменә, игенчелеккә, аш-суга багышлана.

Аның бибәһа мирасы һәм тормышы, күренгәнчә, шактый гына өйрәнелсә дә, бу өлкәдә әле башкарыласы эшләр дә байтак, әлеге актуаль мәсьәләне истә тотып, безнең тарафтан галимгә багышлап төзелгән махсус әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентыкны 2017 елда «Җыен» фонды «Шәхесләребез» сериясендә бастырып чыгарды[2]. Бу зарур эш иде, чөнки, беренчедән, аның моңа кадәр дөнья күргән бас-

---

[1] Мифтах әл-Коръән. 2 томда. Т. 2: Насыйри К. Мифтах әл-Коръән / Фәнни мөх. А. Г. Хәйретдинов, әдәби мөх. Р. Ф. Шәфигуллина; төз., транслит. һәм тәрҗ. итүче, кереш сүз: А. Г. Хәйретдинов; кереш мәкалә: Р. Ф. Шәфигуллина. – Казан: Познание, 2015. – 452 б.

[2] Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / Фәнни мөх. Җ. Миңнуллин; төз. Р. Исламов. – Казан: Җыен, 2017. – 816 б.

малары текстологик эшләнешләре һәм фәнни аппарат биреleше ягыннан шактый тәнкыйтькә мохтаҗ. Икенчедән, аңа бәйле күп кенә архив материаллары, хатлар[1] киң катлау укучыга һаман билгесез кала килә. Өченчедән, шундый олуг затның моңа кадәр аерым тулы библиографиясе төзелмәде. Дүртенчедән, К. Насыйриның шәхесен ниндидер бер җәфа чигүче рәвешендә сурәтләү тенденциясе даими алга сөрелде. Гәрчә, аның исеменә килгән дәгъватнамәләр (чакыру кәгазьләре) галимнең аралашу даирәсен бөтенләй башкача күзалларга ярдәм итә. Күп кенә хезмәтләренең дә хәлле кешеләр, байлар иганәсенә нәшер ителгәнлеген истән чыгармаска кирәк.

К. Насыйриның туган авылы Кече Шырданда алып барылган эшләр турында да әйтеп үтәргә кирәк. Казандагы коммерцияле булмаган җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять «Акведук» проектлау компаниясе (җитәкчесе – Кече Шырданда туып-үскән, галимнең кардәше булган Асия Гобәйдуллина) һәм җирле үзидарә «Каюм Насыйри туган җирне яңартып торгызу» фондын гамәлгә куялар. Фонд авыл халкы белән берлектә Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлар хөрмәтенә куелган һәйкәлне яңартуны (2015), мәчетне сафка бастыруны (2017), Каюм Насыйри коесын, «Тал», «Сабантуй» чишмәләрен төзекләндерүне (2016) һәм «Чәй йорты» төзүне (2018), иске зират коймасы өчен тимер-бетон баганалар һәм әйләнә буенча төрле агачлар утыртуны (2019), Каюм Насыйри исемендәге китапханә-музейның яңа бинасын коруны (2021) оештырды һәм башкарып чыкты. Китапханә-му-

---

[1] Дөрес, К. Насыйри, аның туганнары һәм башка кешеләр белән бәйле хатлардан аерым өземтәләр, кайберләре тулысынча, әдәбият галиме М. Гайнуллин мәкаләрендә, К. Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материалларында (Казан, 1948) урын алган, Казан (Идел буе) федераль университеты Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең сирәк кулъязмалар һәм китаплар бүлегенең баш библиографы Д. Абдуллина (1934–2006) тарафыннан кирилл хәрефләренә күчерелеп, К. Насыйриның дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең өченче томында (2005) бастырылган.

зейда еш кына галимгә багышланган мәдәни чаралар үткәрелә. Зиратта Габделкавинең (1833–1901) кабер ташы, чардуганы яңартылды. Авылдагы XIV–XV гасырларга караган борынгы зиратка ташбилге утыртылды. «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Л. Н. Шәфигуллин тарафыннан К. Насыйри истәлегенә рото́нда эшләнде (2021). Чишмәләрдән су чыга торган урында плотина төзелеп файдалануга тапшырылды (2023).

***

К. Насыйриның библиографиясен булдыруның беренче омтылышы узган гасырның 40 нчы еллары ахырында була. Аерым алганда, М. Гайнуллинның 1945 елда нәшер ителгән «Каюм Насыри: (Его научная и просветительская деятельность)» хезмәтендә «Библиографик күрсәткеч»[1], галимнең тууына 120 ел тулуга багышлап уздырылган гыйльми сессия материаллары җыентыгында «Библиографик белешмәләр» (төзүчесе – М. Гайнуллин) урнашырылган[2]. Ул «Каюм Насыйриның басылып чыккан әсәрләре» һәм «Каюм Насыйри турында рус һәм татар матбугаты» дигән ике өлештән тора.

Белешмәнең тулыландырылган варианты З. Ш. Хәбибуллина тарафыннан 1952 елда аерым китапчык итеп бастырыла[3], К. Насыйриның 1953[4] һәм 1956[5] елларда дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»ендә бирелә.

---

[1] Гайнуллин М. Каюм Насыри (Его научная и просветительская деятельность). К. 120 летию со дня рожд.… – С. 77–83.

[2] Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)… – Б. 142–145.

[3] Татар халкының атаклы галиме, мәгърифәтчесе һәм язучысы Каюм Насыйри (1825–1902): әдәбият исемлеге / Төз. З. Ш. Хәбибуллина; ред. Р. З. Мөхитдинова. – Казан, 1952. – 12 б.

[4] Насыйри К. Сайланма әсәрләр / М. Гайнуллин ред. – Казан: Таткнигоиздат, 1953. – Б. 409–415.

[5] Насыйри К. Сайланма әсәрләр / М. Гайнуллин ред. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 2 басмасы. – Б. 409–415.

Аннан соң К. Насыйриның тууына 150 ел тулу уңаеннан 1975 елның 14 февралендә үткәрелгән конференция материаллары тупланмасында әлеге юбилей чаралары белән бәйле рәвештә матбугатта басылып чыккан мәкаләләрнең исемлеге китерелә[1].

К. Насыйриның Октябрь түнтәрелешенә кадәр һәм аннан соң нәшер ителгән басмалары, вакытлы матбугат һәм аерым җыентыкларга кергән әсәрләре һәм хезмәтләре, аның турындагы әдәбият исемлеге 1975 елда нәшер ителгән ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең икенче томында урнаштырылган[2].

Галим турында берникадәр библиографик белешмәне Г. Г. Батыршинаның «Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге» дип аталган монографик хезмәтендә дә табарга мөмкин[3].

Бөек мәгърифәтченең тулы библиографиясе, беренче тапкыр безнең тарафтан төзелеп, «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык»та бастырылды[4]. Әмма ул соңгы елларда тагын тулыландырылды.

Кызганыч ки, хәзерге вакытка кадәр олуг галимнең биобиблиографик күрсәткече аерым китап итеп нәшер ителгәне булмады. Шуңа күрә, әлеге «ак тап»ны бетерү максатында, К. Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан, 2025 елда Татарстан Республикасында башкарыласы эшләрнең берсе итеп, аны әзерләп бастыру тәкъдим ителде. Күрсәткечнең композицион төзелеше шулай: **I. Хезмәтләре, әсәрләре. II. Мәкаләләре. III. Тормышы һәм иҗаты турында** (монографияләр, диссертация авторефератлары, фәнни җыентыклар, тасвирлама, библиографияләр, буклет, мәкаләләр). **IV. Башка чыганаклардагы мәгълүмат** (монографияләр,

---

[1] Выдающийся просветитель-демократ... – С. 214–215.

[2] Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда... – 2 т. – Б. 289–316.

[3] Батыршина Г. Г. Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге / Г. Г. Батыршина. – Казан: КДАТУ нәшр., 2007. – Б. 141–153.

[4] Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык... – Б. 753–811.

фонд һәм коллекция күрсәткече, уку-укыту әсбаплары, диссертация авторефератлары, энциклопедия мәкаләләре). Анда *татар, башкорт, казакъ, мари, рус, таҗик, төрек, төрекмән, үзбәк, француз* телләрендәге чыганаклар тупланды һәм төп нөсхәләрендә бирелде. Хронологик яктан алар 1860–2024 елларны үз эченә ала.

Бу юнәлештә эш алга таба да бәрәкәтле дәвам иттереләчәгенә ышанасы килә.

***

Эш барышында аерым мәсьәләләрне хәл итүдә күрсәткән ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе М. Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Энциклопедистика үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре докторы, профессор Рафаил Шәйдуллинга, фәнни хезмәткәр Фәридә Камалетдиновага, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директорының фәнни эшләр буенча урынбасары Ирек Һадиевка, Казан (Идел буе) федераль университеты Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Энҗе Сабировага, Шәрык бүлекчәсе китапхәнәчесе Илфира Хәмадка, Россия Фәннәр академиясе «Казан гыйльми үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең үзәк гыйльми китапханәсе мөдире Миләүшә Әхмәтовага, баш китапханәче Наталья Горшковага, әйдәп баручы китапханәчеләр Лилия Садыйковага һәм Ксения Мохтасаровага рәхмәтләремне белдерәм.

***Рәмил Исламов,***
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе,*
*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән*
*министрлыгының*
*Каюм Насыйри исемендәге премиясе лауреаты*

# I
# ХЕЗМӘТЛӘРЕ, ӘСӘРЛӘРЕ
## Татар телендә

**Әнмүзәҗ** (Лисанымызның сарыф вә нәхү кагыйдәләре бәянында). Тәҗрибә йөзеннән әүвәл мәртәбә Габделкаюм Габденнасыйр угылы тасниф кылды. Казан, 1313 сәнә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 30 нчы июньдә 1895 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1895 нче елда. – 87 б.

**Әнмүзәҗ фиән-нәхү.** Наширләре: Борадәран Кәримовлар. – Казань: Электро-тип. Т. Д. «Бр. Каримовы», 1910. – 172 б. [калган битләре юк].

**Әфсанәи Гөлрох вә Камәрҗан.** Чин падишаһының кызы Гөлрох белән Харәзем шаһы угылы Камәрҗанның мажарасыдыр ки лисане әҗнәби үзә. Роман. Габделкаюм Габденнасыйр угылы ән-Насыйри. Казан, 1896 сәнәдә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербургта 20 нче май 1896 нчы елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1896 нчы елда. – 54 б.

*Рец.: Катанов Н. «Афсанэ-и Гюлрух ве Камарджан» (история Гюльрух и Камарджана). Казань, 1896. Тип. ун-та. 54 стр. в 8 д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1897. – № 4. – С. 261–263.*

**Әхлак рисаләсе.** Балаларга явыз холыктан сакланып изге холык белән холыкланмак өчен ата-ана нәсыйхәте мәнзилендә бер нәсыйхәттер. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының иҗтиһад әсәреннән балаларга әхлак тәгълим өчен бер тарикатьтер. 1298 сәнә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 23 нче март 1881 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр әүвәл мәртәбә 1881 нче елда. – 32 б.

**Әхлак рисаләсе.** Балаларга явыз холыктан сакланып изге холык белән холыкланмак өчен ата-ана нәсыйхәте мәнзилендә бер нәсыйхәттер. Габделкаюм мулла Габденнасыйр

угылының әсәреннән балаларга әхлак тәгълим өчен бер тарикатьтер. 1302 сәнә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 15 нче сентябрь 1884 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр икенче мәртәбә 1884 нче елда. – 24 б.

**Әхлак рисаләсе вә һәм форузы могтәкыйдәт рисаләсе вә дәхи әхәдис кодсиядән мөгаззиләрдер ки, өч рисаләдән гыйбарәт бер китапчыктыр, балаларның күңеленә забыт кылдырмак өчен мәнфәгатьле бер әсәрдер. Габделкаюм Габденнасыйр угылының мөәллифәтеннәндер.** 1307 сәнә. Бу китапның басмасына рөхсәт вирелде Петербурхта 1 нче майда 1890 нчы елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр икенче мәртәбә 1890 нчы елда. – 39 б.

**Әхлак рисаләсе.** Балаларга явыз холыктан сакланып изге холык белән холыкланмак өчен ата-ана нәсыйхәте мәнзилендә нәсыйхәттер. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының әсәреннән балаларга әхлак тәгълим өчен бер тарикатьтер. 1310 сәнә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде шәһре Казанда 17 нче декабрьдә 1892 нче елда. Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр өченче мәртәбә 1893 нче елда. – 24 б.

**Әхлак рисаләсе.** Балаларга явыз холыктан сакланып изге холык илән холыкланмак өчен ата-ана нәсыйхәте мәнзилендә нәсыйхәттер. Габделкаюм Габденнасыйр угылының әсәреннән балаларга әхлак тәгълим өчен бер тарикатьтер. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербургта 20 нче ноябрьдә 1898 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1898 нче елда. – 24 б.

*Рец.: Катанов Н. «Ахляк рисалесы» (о характерах). Казань, 1898. Тип. ун-та. 24 страниц в 12 д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1898. – № 5. – С. 265.*

**Әхлак рисаләсе вә һәм форузы могтәкыйдәт рисаләсе вә дәхи әхәдис кодсиядән мөгаззиләрдер ки, өч рисаләдән гыйбарәт бер китапчыктыр, балаларның күңеленә забыт**

**кылдырмак өчен мәнфәгатьле бер әсәрдер**. **Габделкаюм Габденнасыйр угылының мөәллифәтеннәндер.** 1307 сәнә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 27 нче ноябрьдә 1900 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр Казан өязе Түбән Әйшә авылының Исмәгыйль Нәҗметдин угылы Шәмсетдиновның хәраҗәте илән 1901 нче елда. – 44 б.

**Әхлак рисаләсе.** Балаларга явыз холыктан сакланып изге холык илән холыкланмак өчен ата-ана нәсыйхәте мәнзилендә нәсыйхәттер. Габделкаюм Габденнасыйр угылының әсәреннән балаларга әхлак тәгълим өчен бер тарикатьтер. Нашире: Казанда китапчы Исмәгыйль Шәмсетдинов. – Казань: Типолитогр. Имп. Казан. ун-та, 1904. – 24 б.

**Әхлак рисаләсе.** Ибтидаи мәктәпләрнең соңгы сыйныфлары өчен. Габделкаюм ән-Насыйри. Нашире: «Сабах» ширкәте. Казан, Уфа. Бишенче мәртәбә басылды. – Казань: Электро-тип. «Умид», 1913. – 24 б.

**Буш вакытларда укырга сүзләр.** Берничә төрле нәрсәләр хакында. Бу дөньяда ни нәрсәләр бар, ни эшләр бар – белергә мәел итүчеләрне белешләндерер өчен. Габделкаюм Габденнасыйр угылы тәэлиф итеп бастырды. 1284 [Казан, 1867]. – 44 б.

**Габделкаюм Насыйри әсәре.** «Буш вакыт»тан беренче җөзьә. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе. – Казань: Типо-литогр. Н. М. Чижовой, 1909. – 32 б.

**Габделкаюм Насыйри әсәре.** «Буш вакыт»тан икенче җөзьә. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе. – Казань: Типо-литогр. Н. М. Чижовой, 1909. – 32 б.

**Габделкаюм Насыйри әсәре.** «Буш вакыт»тан өченче җөзьә. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе. – Казань: Типо-литогр. Н. М. Чижовой, 1909. – 32 б.

**Габделкаюм Насыйри әсәре.** «Буш вакыт»тан дүртенче җөзьә. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе. – Казань: Типо-литогр. Н. М. Чижовой, 1909. – 32 б.

**Габделкаюм Насыйриның «Буш вакыт» исемле әсәреннән бишенче җөзьә.** Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе. – Казань: Типо-литогр. Н. М. Чижовой, 1909. – 32 б.

**Гакаид рисаләсе.** Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының мөәлләфатеннәндер. Казанда Вячеславның басмаханәсендә табыг кылынды. 1300 сәнә (икенче мәртәбә). Ошбу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербургта 20 нче августта 1882 нче елда. Мөхәммәтнәҗип Галиәкбәр угылының хәраҗәте илән. – 24 б.

**Гакаид рисаләсе.** Габделкаюм Габденнасыйр угылының мөәлләфатеннәндер. Казанда Казан университетының басмаханәсендә табыг улынды 1896 нчы сәнәдә өченче мәртәбә. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 30 нчы апрельдә 1896 нчы елда. – 24 б.

> *Рец.: Катанов Н. «'Акаид рисалесы» (послание относительно вероучения). Казань, 1896. Тип. ун-та. 24 стр. в $8^0$ д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1897. – № 12. – С. 692.*

**Гакаиде Исламия.** Мән мөәллифәт Габделкаюм Әбелхәер. 1867. Бу китап басма улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә Габделкаюм Габденнасыйр угылының хәраҗәте илән 1283 нче сәнәдә [1867]. – 23 б.

**Гөлзар вә чәмәнзар, ягъни үләнлек вә чәчәклек.** Хәвасы нәбатат бәянында бер китаптыр ки, мәмләкәтемездә ике әҗзаханә сахибләре тасниф кылмышлардыр 1885 сәнәдә. Аннан без тәрҗемә кылып интишарына сәгый кылдык Габделкаюм Габденнасыйр угылы əн-Насыйри 1310 сәнәдә. Ошбу китапта мәзкүр нәбататның русча вә һәм латинча исемнәре тәрҗемә кылынып мең сигез йөз сиксән сигезенче елгы календарьда басылмыш иде. Китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 13 нче ноябрьдә 1893 нче елда. – Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1894 нче елда. – 112+16 б.

**Гөлзар вә чәмәнзар, ягъни үләнлек вә чәчәклек.** Икенче мәртәбә басылуы. Хәвасы нәбатат бәянында бер китаптыр

ки, мәмләкәтемездә ике әҗзаханә сахибләре тасниф кылмышлардыр 1885 нче сәнәдә. Аннан без тәрҗемә кылып интишарына сәгый кылдык Габделкаюм Габденнасыйр угылы ән-Насыйри 1310 нчы сәнәи һиҗриядә. Ошбу китапта мәзкүр нәбататның русча вә һәм латинча исемнәре тәрҗемә кылынып 1888 нче елгы календарьда басылмыш иде. Нашире: Казанда китапчы Исмәгыйль Шәмсетдинов. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1903. – 112 б.

**Гыйльме һәндәсә, ягъни һәндәсә фәнендә бер кечерәк китаптыр ки, ибтида бәгъзе шәкертләремә ифадә өчен тасниф кылдым Габделкаюм ән-Насыйри.** Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1895 нче елда. – 24 б.

**Җәваһир әл-хикәят вә л-әсилә вәләтаиф әр-риваять вә әл-әмсилә.** Тәрҗемә мин «Китаб әнис әл-җәлис» лил-имам әс-Соютый рәхмәте Аллаһы мин мөәлләфат Габделкаюм ибне мулла Габденнасыйр әш-Шырдани 1300 сәнәи һиҗрия. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 7 нче сентябрьдә 1883 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1884 нче елда. – 139 б.

**Җәваһир әл-хикәят вә л-әсилә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-әмсилә.** Тәрҗемә мин «Китаб әнис әл-җәлис» лил-имам әс-Соютый рәхмәте Аллаһы мин мөәлләфат Габделкаюм мулла Габденнасыйр әш-Шырдани 1304 сәнәи һиҗрия (икенче мәртәбә). Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 30 нчы ноябрьдә 1886 нчы елда. Бу китап басма улынмыштыр Казан университеты табыгханәсендә 1887 нче елда. – 139 б.

**Җәваһир әл-хикәят вә л-әсилә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-әмсилә.** Тәрҗемә мин «Китаб әнис әл-җәлис» лил-имам әс-Соютый рәхмәте Аллаһы мин мөәлләфат Габделкаюм ибне мулла Габденнасыйр әш-Шырдани 1307 сәнәи һиҗрия (өченче мәртәбә). Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 14 нче мартта 1889 нчы елда. Бу китап басма

улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә 1889 нчы елда. – 139 б.

**Җәваһир әл-хикәят вә л-әсилә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-әмсилә.** Тәрҗемә мин «Китаб әнис әл-җәлис» лил-имам әс-Соютый рәхмәте Аллаһы мин мөәлләфат Габделкаюм ибне мулла Габденнасыйр әш-Шырдани 1312 сәнәи һиҗрия (дүртенче мәртәбә). Бу китап басма улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә 1894 нче елда. – Казань: Тип. Имп. ун-та, 1894. – 138 б.

**Җәваһир әл-хикәят вә л-әсилә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-әмсилә.** Тәрҗемә мин «Китаб әнис әл-җәлис» лил-имам әс-Соютый рәхмәте Аллаһы мин мөәлләфат Габделкаюм ибне мулла Габденнасыйр әш-Шырдани 1315 сәнәи һиҗрия (бишенче мәртәбә басылмыштыр). Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 15 нче ноябрьдә 1897 нче елда. Бу китап басма улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә 1898 нче елда. – 136 б.

*Рец.: Катанов Н. «Джауагиру'ль-хикаят уа'ль-асиле уа лятаифу'р-риуаять уа'ль-амсиле» (драгоценности рассказов и вопросы, остроумия, предания и притчи). Казань, 1898. Тип. ун-та. 136 стр. в $8^0$ д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1898. – № 8–9. – С. 428.*

**Җәваһир әл-хикәят вә л-әсилә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-әмсилә.** Тәрҗемә мин «Китаб әнис әл-җәлис» лил-имам әс-Соютый рәхмәте Аллаһы мин мөәлләфат Габделкаюм ибне мулла Габденнасыйр әш-Шырдани 1318 сәнәи һиҗрия (алтынчы мәртәбә басылмыштыр). Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр Казан өязе Түбән Әйшә авылының Исмәгыйль Нәҗметдин угылы Шәмсетдиновның хәраҗәте илән 1900 нче елда. – 123 б.

*Рец.: Катанов Н. «Джауагиру'ль-хикаят уа'ль-асиле уа лятаифу'р-риуаять уа'ль-амсиле» (драгоценности рассказов и вопросы, остроумия, предания и притчи). Казань, 1900. Типо-литогр. ун-та. 123 стр. в $6^0$. / Н. Катанов // Деятель. – 1901. – № 5. – С. 248.*

**Җәваһир әл-хикәят вә л-әсилә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-әмсилә.** Тәрҗемә мин «Китаб әнис әл-җәлис» лил-имам әс-Соютый рәхмәте Аллаһы мин мөәлләфат Габделкаюм ибне мулла Габденнасыйр әш-Шырдани 1423 сәнәи һиҗрия (җиденче мәртәбә басылмыштыр). Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр Казан өязе Түбән Әйшә авылының Исмәгыйль Нәҗметдин угылы Шәмсетдиновның хәраҗәте илән 1905 нче елда. – 123 б.

**Зирагать гыйлеме, ягъни иген икмәк вә ашлык сачмәк, вә җимеш бакчалары әхйа кылмак бәянында бер яңа фәндер.** Габделкаюм Габденнасыйр угылының истихраҗатеннән. Казан, 1310 сәнә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде шәһре Казанда 25 нче сентябрьдә 1892 нче елда. Бу китап басма улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә 1892 нче елда. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1892. – 24 б.

**Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь ягъни ошбу китап Русь тәварихыннан бер кечкенә рисаләдер ки, моталәга кылып чыккан адәмнәр тәмам Русь тәварихына мәтълаг булырлар.** Ибтида тәварих фәненнән мәгърифәт хасыйл итмәк өчен рус кавеменең могтәбәр тәварихыннан тәрҗемә кылдым Габделкаюм Габденнасыйр угылы. 1307 сәнә. Басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 20 нче апрельдә 1890 нчы елда. Ошбу тәварих Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр Габделкаюм Габденнасыйр угылының хәраҗәте илән әүвәл мәртәбә 1890 нчы елда. – Казань: Тип. Имп. ун-та, 1890. – 27 б.

**Игъланат.** Ошбу дәфтәрдә фәкыйрь Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының 1859 нчы елдан 1897 нче елга кадәр тасниф итеп бастырган һәркайсы календарьның вә китапларның тәгърифләре бер фиһрис мәнзилендә бәян кылыныр, чөнки фөнүне шәттидән бәгъзы мәгълүмат язылмыш булып мәсәлән. Ошбу игъланатның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 20 нче сентябрьдә 1896 нчы елда. Ошбу игъланат Казан университетының табыгханәсендә басма

улынмыштыр 1896 нчы елда. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1896. – 40 б.

**Иҗек.** Ибтидаи сәбыйкка шөругъ кыйлгучы балаларга иҗек танытмак өчен бер тәҗрибәдер. Габделкаюм ән-Насыйри. 1313 сәнәи һиҗрия. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 14 нче октябрьдә 1895 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1895 нче елда. – 20 б.

**Иршад әл-әтбихә ила истихзар әл-әтгамә ягъни кагыйдәчә тәгам хәзерләмәк бәянында бер фәндер.** Җөзьәи әүвәл. Габделкаюм Габденнасыйр угылының әсәре иҗтиһадияседер. Казан, 1310 сәнә. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 22 нче майда 1893 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1893 нче елда. – 30 б.

**Иршад әл-әхба ила тәгълим әлифба.** Балаларны иҗеккә төшендермәк өчен гадәте кадим үзрә бер тәгълимдер. Ибтидаи сәбыйкка шөругъ кыйлгучы балаларга иҗек танытмак өчен бер тәҗрибәдер. Бер бала гайбер сарыф булмаса моны чыккач тугры «Һәфтияк» сүрәсенә төшәр. Ике-өч бала ошбу тарикча иҗеккә тиз төшенмешләр иде. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының таснифәтеннәндер. 1313 сәнәи һиҗрия. Казан өязе Түбән Айшә авылының Исмәгыйль Нәҗметдин угылы Шәмсетдиновның хәраҗәте белән Казанның университет матбагасында икенче мәртәбә табыг вә тәмсил кылынды. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1901. – 26 б.

**Исереклек заманы.** Моннан егерме биш ел элек. Исереклек хәлләре бәянында. Әсәр: Габделкаюм ән-Насыйри. Нашире: Шәмсетдин Хөсәенов вәрәсәсе. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде 20 нче ноябрьдә 1895 нче елда. Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1896 нчы сәнәдә. – 24 б.

*Рец.: Катанов Н. «Исриклик халляры беянында гибретнаме» (книга примеров относительно обстоятельств*

*пьянства). Казань, 1896. Тип. ун-та. 24 стр. в 8 д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1897. – № 1. – С. 56–60.*

**Истыйлахәте гыйльме һәндәсә, ягъни һәндәсә фәненедә бер кечерәк китаптыр ки, ибтида бәгъзы шәкертләремә ифадә өчен тасниф кылдым Габделкаюм ән-Насыйри.** Шәһре Казан, 1313 сәнәи һиҗрия. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 30 нчы июньдә 1895 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1895 нче елда. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1895. – 87 б.

**Истыйлахате җәгърәфия.** Ибтида җәгърәфия фәненнән дәрес башлагучылар өчен олуг җәгърәфиямдән ихтисар кылдым Габделкаюм Габденнасыйр угылы. Казан, 1307 сәнә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 8 нче майда 1890 нчы елда. Бу китап басма улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә 1890 нчы елда. – 74 б.

**Кабуснамә тәрҗемәсе.** Кәйкавус бине Искәндәр падишаһ үзенең угылына язган нәсыйхәтләредер. Кырык дүрт баб үзә тасниф кылынып тәрҗемәсендә бераз ихтисар кылынды. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының тәрҗематеннәндер. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 1 нче апрель 1882 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1300 елда һиҗрия. – 140 б.

**Кабуснамә тәрҗемәсе.** Кәйкавус бине Искәндәр падишаһ үзенең угылына язган нәсыйхәтләредер. Кырык дүрт баб үзә тасниф кылынып тәрҗемәсендә бераз ихтисар кылынды. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының тәрҗематеннәндер икенче мәртәбә. Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1898 сәнәдә. – 140 б.

*Рец.: Катанов Н. «Кабус-намэ тэрджемесы» (перевод книги Кабус-намэ). Казань, 1898. Тип. ун-та. 140 стр. в 8 д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1898. – № 5. – С. 264–265.*

**Кавагыйде китабәт, ягъни тасниф вә имля кагыйдәләрен бәян кыйлгучы бу бер яңа фәндер ки, бер сахибе әл-фөнүн моталәга кыйлып мәфһүменә төшенсә, ифадәи шифаһиядә вә ифадәи тәхририядә хатадан саклана белер.** Мөхәррире Габделкаюм ән-Насыйри. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 7 нче сентябрьдә 1892 нче елда. Бу китап басма улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә 1892 нче елда. – 26 б.

**Кавагыйде лисане гарәб, ягъни гыйльме сарыфтан вә гыйльме нәхүдән:** Бөдан вә гавамил вә һәм әнмүзәҗ мәтененнән гыйбарәт вә ике фәнне мөштәмәл бер китаптыр ки, укырга вә хифыз кылырга сәһел тарыйкча тәртип кылынды (Зирәк балаларга берьеллык сәбыйктыр). Әһле тиҗар балаларына сәһел заманда бу ике фәнне зарурәт кадер тәхсил өчен интихаб вә ихтисар кылдым Габделкаюм ән-Насыйри (Казан, 1313 сәнәдә). Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1896 нчы елда. – 74 б.

*Рец.: Катанов Н. Книга «Кава'иди-лисани-'араб» (правила арабского языка), составлена Абду'ль-Каюмом Насыровым. Казань, 1896. Тип. ун-та. 74 стр. в 8 д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1897. – № 2. – С. 119–120.*

**Казан календаре 1871 нче елга.** Берничә урысча календарьлардан тәрҗемә вә тәэлиф кылып Габделкаюм Габденнасыйр угылы басма кылдырды Ибраһим Габдерәшит угылы Абдуллинның хәраҗәтеннән. [1871] – 64 б.

**Казан календаре 1872 нче елга.** Икенче ел ([18]72 нче ел кәбисә елы булып, 366 көн киләә). Габделкаюм Габденнасыйр угылы иҗат вә тасниф итеп икенче мәртәбә басма кылдырдым Казанда университет типографиясендә. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Казанда 1871 нче елда ноябрьнең 6 нчы көнендә. – 80 б.

**Казан календаре 1873 нче елга.** Өченче ел (кәбисә елының соңындагы әүвәлге ел, 365 көн). Габделкаюм Габденнасыйр угылы иҗат вә тасниф итеп өченче мәртәбә басма

кылдырдым Казанда университет типографиясендә, 1873. – 64 б.

**Казан календаре 1874 нче елга.** Дүртенче ел (кәбисә елыннан соң икенче ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп дүртенче мәртәбә басма кылдырдым Габделкаюм Габденнасыйр угылы Мөхәммәтҗан Мифтахетдин угылының хәраҗәтеннән Казанда университет табыгханәсендә, 1874. – 52 б.

**Казан календаре 1875 нче елга.** Бишенче ел (кәбисә елыннан соң өченче ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп бишенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы Казан мещаны Шаһиәхмәт Сөләйман угылы Биккиниевнең хәраҗәте илән 1875 нче елда. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 9 нчы март 1875 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр. – 59 б.

**Казан календаре 1876 нчы елга.** Алтынчы ел (кәбисә елы, 366 көн). Иҗат вә тасниф итеп алтынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы Мөхәммәтнәҗип Галиәкбәр угылының хәраҗәтеннән. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 24 нче ноябрь 1875 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр [1875 нче елда]. – 48 б.

**Казан календаре 1877 нче елга.** Җиденче ел (кәбисә елы артындагы ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп җиденче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 6 нчы ноябрь 1876 нчы елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1876 нчы елда. – 56 б.

**Календарь 1878 нче елга.** Сигезенче ел (кәбисә елы артындагы икенче ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп сигезенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 3 нче октябрь 1877 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1877 нче елда. – 32 б.

**Календарь 1879 нчы елга.** Тукызынчы ел (кәбисә елы артындагы өченче ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп сигезенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 24 нче июль 1878 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1878 нче елда. – 56 б.

**Календарь 1880 нче елга.** Унынчы ел (кәбисә елы, 366 көн). Иҗат вә тасниф итеп унынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 4 нче февраль 1880 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1880 нче елда. – 38 б.

**Календарь 1881 нче елга.** Унберенче ел (кәбисә елы артыннан әүвәлге ел, 365 көн). Тасниф итеп унберенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 4 нче август 1880 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1880 нче елда. – 56 б.

**Календарь 1882 нче елга.** Елкы елы. Уникенче ел (кәбисә елы артыннан икенче ел, 365 көн). Тасниф итеп уналтынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 8 нче октябрьдә 1881 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1881 нче елда. – 51 б.

**Календарь 1883 нче елга.** Куй елы. Унөченче ел (кәбисә елы артыннан өченче ел, 365 көн). Тасниф итеп унөченче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы әш-Шырдани. Басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 1882 нче елда август 25-ендә. Казанда Перовның ташбасмаханәсендә табыг кылынды [1883 нче елда]. – 40+8 б.

**Календарь 1884 нче елга.** Пичин елы. Ундүртенче ел (кәбисә елыдыр, 366 көн). Тасниф итеп ундүртенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 7 нче сентябрьдә

1883 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1883 нче елда. – 40 б.

**Календарь 1885 нче елга.** Тавык елы. Унбишенче ел (кәбисә елы артыннан беренче ел, 365 көн). Тасниф итеп унбишенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 9 нчы октябрьдә 1884 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1884 нче елда. – 50 б.

**Календарь 1888 нче елга.** Сычкан елы. Уналтынчы ел (кәбисә елы, 366 көн). Тасниф итеп уналтынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 1 нче декабрьдә 1887 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1887 нче елда. – 52 б.

**Календарь 1889 нчы елга.** Сыгыр елы. Унйиденче ел (кәбисә елы артыннан әүвәлге ел, 365 көн). Унйиденче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарьның басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 1 нче декабрьдә 1888 нче елда. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1888 нче елда. – 45 б.

**Календарь 1890 нчы елга.** Барс елы. Унсикезенче ел (кәбисә елы артыннан икенче ел, 365 көн). Унсикезенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарьның басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 9 нчы гыйнварда 1890 нчы елда. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1890 нчы елда. – 45 б.

**Календарь 1891 нче елга.** Барс елы. Унтукызынчы ел (кәбисә елы артыннан өченче ел, 365 көн). Унтукызынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 5 нче июльдә 1890 нчы елда. Ошбу китап Казан уни-

верситетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1890 нчы елда. – 35 б.

**Календарь 1892 нче елга.** Ләү елы. Егерменче ел (кәбисә ел, 366 көн). Егерменче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарьның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 16 нчы августта 1891 нче елда. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1891 нче елда. – 48 б.

**Календарь 1893 нче елга.** Җылан елы. Егерме беренче ел (кәбисәдән соң, 365 көн). Егерме беренче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарьның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 7 нче сентябрьдә 1892 нче елда. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1892 нче елда. – 47 б.

**Календарь 1894 нче елга.** Елкы елы. Егерме икенче ел. Егерме икенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарьның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 4 нче октябрьдә 1893 нче елда. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1893 нче елда. – 71 б.

**Календарь 1896 нчы елга.** Егерме бишенче ел (кәбисә ел, 366 көн). Өч елны тарых кылынып егерме биш елдан бирле чыгадыр. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының таснифыдыр. Ошбу календарьның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 23 нче сентябрьдә 1895 нче елда. Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1895 нче елда. – 22 б.

**Календарь 1897 нче елга.** 26 нчы ел (кәбисә елы артыннан әүвәл ел, 365 көн). Өч елны тарых кылынып егерме алты елдан бирле чыкадыр (Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының таснифыдыр). Ошбу календарьның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 20 нче сентябрьдә 1896 нчы елда. Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1896 нчы елда. – 49 б.

**Кырык бакча.** Мостатраф сүзләре вә һәм голәмаи Зәмәхшәринең раузасы өслүбе үзә бакча тәсмия кылынды. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының мәҗмугасыннан. Бу китапны басмага рөхсәт бирелде Петербурх 25 ноябрьдә 1880 нче елда. Казанда Перовның ташбасмаханәсендә табыг кылынды 1298 сәнәдә [1880]. – 58 б.

**Кырык бакча.** Мостатраф сүзләре вә һәм голәмаи Зәмәхшәринең раузасы өслүбе үзә бакча тәсмия кылынды. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының мәҗмугасыннан. Бу китапны басмага рөхсәт бирдем Габделмән Габделхәй угылы Казанскийга Габделкаюм Насыйров. Бу китап басма улынды Казанда матбагаи Кәримиядә 1902 нче сәнәдә. Бу китапның басмасына Петербурх цензоры тарафыннан рөхсәт вирелмештер 5 нче апрельдә 1902 нче сәнәдә. – 80 б.

**Кырык вәзир кыйссасы.** Госманлы теленнән тәрҗемә кылынып Казанда икенче мәртәбә басылды университет табыгханәсендә Казан мещаны Әхмәтсафа Хөнҗәр угылы Хәмзиннең хәраҗәте илән 1290 [1874] нчы елда. – 148 б.

**Кырык вәзир кыйссасы.** Госманлы теленнән тәрҗемә кылынып Казанда дүртенче мәртәбә басылды (Габделкаюм Габденнасыйр угылының тәрҗематеннәндер). Басмак җаиз 15 нче ноябрьдә 1890 нчы елда Петербурхта. Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1891 нче елда. – 160 б.

**Кырык вәзир кыйссасы.** Госманлы теленнән тәрҗемә кылынып Казанда алтынчы мәртәбә басылды. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының тәрҗематеннәндер. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр Казан өязе Түбән Әйшә авылының Исмәгыйль Нәҗметдин угылы Шәмсетдиновның хәраҗәте илән 1900 нче елда. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1900. – 160 б.

*Рец.: Катанов Н. «Кырык везир кыссасы» (сказки 40 везирей). Казань, 1900. Тип. ун-та. 160 стр. в 8 д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1901. – № 5. – С. 248.*

**Кырык вәзир кыйссасы.** Госманлы теленнән тәрҗемә кылынып Казанда йиденче мәртәбә басылды. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының тәрҗематеннәндер. Нашире: Китапчы Исмәгыйль Нәҗметдин угылы Шәмсетдинов Казанда. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1907. – 160 б.

**Кырык вәзир кыйссасы.** Госманлы теленнән тәрҗемә кылынып Казанда сигезенче мәртәбә басылды. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының тәрҗематеннәндер. Нашире: Исмәгыйль Шәмсетдинов Казанда. – Казань: Тип. В. Л. Домбровского, 1910. – 160 б.

**Ләһҗәи татари, ягъни татар телендә мәүҗүд булган әлфаз гали тәртип әл-хоруф һәркайсы үзә мәкамендә зикер кылынып морадифлары белән тәфсир ителде.** Габделкаюм Габденнасыйр угылының тәэлифәтеннәндер. 1895 сәнәдә. Җилди әүвәл. Бу китапның басмасына рөхсәт бирелде Санкт-Петербурхта 4 нче февральдә 1895 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1895 нче елда. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1895. – 226 б.

**Ләһҗәи татари, ягъни татар телендә мәүҗүд булган әлфаз гали тәртип әл-хоруф һәркайсы үзә мәкамендә зикер кылынып морадифлары белән тәфсир ителде.** Габделкаюм Габденнасыйр угылының тәэлифәтеннәндер 1892 сәнәдә. Җилди сани. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1896 нчы елда. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1896. – 106 б.

*Рец.: Катанов Н. «Легдже-и татари» (толковый татарский словарь). Часть I, 1895. 226 стр. в 6 д. л. – Часть II, 1896. 106 стр. в 6 д. л. Тип. ун-та / Н. Катанов // Деятель. – 1897. – № 3. – С. 201–202.*

**Мәҗмәгу әл-әхбар.** Габделкаюм Габденнасыйр угылы җәмегъ вә тәртип кылдым мең дә сигез йөз дә илле сигезенче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1895 нче елда. – Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1895. – 176 б.

**Мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәт.** Бу бер рисаләдер ки, һәрбер әгъзаның хикмәте холкыясын вә хифзы сыйххәтенең канун вә кагыйдәсен бәян кылыр. Җәмегъ вә тәэлиф кылды Габделкаюм Габденнасыйр угылы 1308 нче сәнәдә. Ошбу мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәтнең басмасына рөхсәт вирелде Санкт-Петербурхта 4 нче октябрьдә 1893 нче елда. Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1893 нче елда. – 71 б.

**Мифтах әл-Коръән.** 2 томда. Т. 2: Насыйри К. Мифтах әл-Коръән: Коръән сүзләренең әлифба тәртибендәге тулы сүзлеге / Фәнни мөх. А. Г. Хәйретдинов, әдәби мөх. Р. Ф. Шәфигуллина; төз., транслит. һәм тәрҗ. итүче, кереш сүз А. Г. Хәйретдинов; кереш мәкалә Р. Ф. Шәфигуллина / К. Насыйри. – Казан: Познание, 2015. – 452 б.

*Рец.: Sibgatullina E. T. Kelâm Şerif (faksimile Kur'an metni); Miftâhu'l-Kur'ân, Kayyûm Nâsırî, hazırl. A. G. Hayretdinov – R. F. Şafigullına, I-II, Kazan: Poznaniye Neşriyatı, 2015 / E. T. Sibgatullina // İslâm Araştırmaları Dergisi. – 2016. – S. 175–204.*

**Мохтәсар тәварих әнбия галәйһем әс-сәлам...** Тәварих фәненнән гаять кирәклесе вә әһле исламнан һәркемгә белмәклеге лязим булган тәварих әҗмәледер. Ибтида тәварих фәненнән балаларга укытыр өчен тасниф кылынды могтәбәр тәварих китапларыннан Габделкаюм Габденнасыйр угылының. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 15 нче сентябрендә 1884 нче елда. Ошбу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1884 нче елда. – 78 б.

**Мохтәсар тәварих әнбия галәйһем әс-сәлам.** Тәварих фәнендә гаять кирәклесе вә әһле исламнан һәркемгә белмәклеге лязим булган тәварих әҗмәледер. Ибтида тәварих фәненнән балаларга укыту өчен «Мират әл-каинәт» вә «Тарихы Табари» вә «Мөхәммәдия» кебек могтәбәр тәварих китапларыннан тасниф кылды Габделкаюм Габденнасыйр угылы 1884 нче елда. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде Санкт-

Петербурхта 25 нче июньдә 1898 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1899 нчы елда. – 79 б.

*Рец.: Катанов Н. Мухтасар-и тауарих-и амбия (краткие биографии пророков). Казань, 1899. Типо-литогр. ун-та. 79 стр. 8 д. л. / Н. Катанов // Деятель. – 1900. – № 2. – С. 105–107.*

**Насыйри К. Әбүгалисина** / Зур яшьтәге балалар өчен кыск. эшл. Г. Лотфи / К. Насыйри. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 84 б.

**Насыйри К. Әбүгалисина** / Зур яшьтәге балалар өчен кыск. эшл. Г. Лотфи. 2 нче басма / К. Насыйри. – Казан: Татгосиздат, 1950. – 80 б.

**Насыйри К. Әбүгалисина** / Кыск. эшл. Г. Лотфи. 3 нче басма; урта һәм олы яшьтәге балалар өчен / К. Насыйри. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 89 б.

**Насыйри К. Әбүгалисина** / Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен. 4 нче басма; кыск. эшл. Г. Лотфи / К. Насыйри. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 67 б.

**Насыйри К. Әбүгалисина.** 5 нче басма / Балалар өчен кыск. эшл. Г. Лотфи / К. Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 63 б.

